ЯҢА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

16+



# КИТАП

**МАРАТ КӘБИРОВ**

Марат Кәбиров

# Китап (роман)

«ЛитРес: Самиздат»

2017

**Кәбиров М.**

Китап (роман) / М. Кәбиров — «ЛитРес: Самиздат», 2017

Китап сөючеләр өчен кызыклы бүләк — «Китап» романы. Антиутопия жанрына караган бу әсәрдә автор китаплар һәм китап укучылар юкка чыкканнан соңгы тормышны күзаллый. Белемнән, тәрбиядән һәм мәдәнияттән ваз кичкән кешелек, әлбәттә, коточкыч сынауларга дучар була. Роман көтелмәгән маҗаралар белән мавыктырып кына калмас, бүгенге вакыйгаларга башкачарак карарга мәҗбүр итәр.

© Кәбиров М., 2017
© ЛитРес: Самиздат, 2017

**Пролог**

Син бу китапны әле укымассың. Син бит эш кешесе. Анда чабасың, монда чабасың… Көне буе шулай пыр тузып йөрисең дә арып кайтып егыласың. Китап укырга синең вакытың юк.

Син бу китапны олыгайгачрак, бераз акыл кереп, минем шикелле күзлек киеп йөри башлагач, кулыңа алырсың… Өйдәге иске-москыларны чыгарып түгәргә дип чүп капчыгына тутырганда, тузанланып беткән шушы китап кулыңа эләгер дә, син аны капчыктан кире алып актарып карарсың. Юк, укырга теләп түгел. Озак еллар буена шүрлегеңдә тузан җыеп яткан шушы нәрсәне элегрәк чыгарып атмавыңа гаҗәпләнеп, аның чынлап та сукыр бер тиенгә тормавына тагы бер кат ышанырга теләп актарып карарсың да бер-ике җөмләсен укып өлгерерсең…

Һәм…

…әле генә нинди эш белән маташуыңны тәмам онытып, бирелеп укырга керешерсең.

…соңгы битенә кадәр укып бетермичә туктала алмассың.

…бөтенләй башка дөньяда, бөтенләй бүтән кеше булып уянып китәрсең.

Һәм үзеңнең бу китапны ник элегрәк, яшьрәк чагыңда укымавың өчен үкенерсең. Әлеге хис синең бөтен булмышыңны биләп алыр. Тормышыңның иң кадерле бер өлешен, мәңгегә дә кире кайтарып булмый торган мөһим бер нәрсәсен югалткандай булып, озак йөрерсең. «Эх, нигә элегрәк укымадым икән бу китапны?.. Элегрәк укысам, барысы да башкача була алыр иде бит…» – дип әрнерсең. Ләкин бернәрсә дә үзгәртә алмассың. Һәм үкенечең җаныңда тырмашып яшәр.

Юк…

Син бу китапны әле укымассың…

Синең аңа әле вакытың юк…

Синең эшләрең күп…

Шундый хәлләр.

**1. Куркыныч кеше**

*Знаете ли вы, почему так важны такие книги, как эта? Потому что они обладают качеством. У этой книги есть поры, она дышит. У нее есть лицо. Ее можно изучать под микроскопом. И вы найдёте в ней жизнь, живую жизнь, протекающую перед вами в неисчерпаемом своём разнообразии.*

*Хорошие писатели тесно соприкасаются с жизнью.*

*Рей Брэдбери*

**1**

– Юк! Юк… – Ирнең ишек артыннан ишетелгән тавышы тынлыкта иркәләнеп утырган өйне селкетеп куйгандай тоелды. – Юк, моның булуы мөмкин түгел…

Хатын үз бүлмәсеннән башын тыгып бераз карап торды да ишек янына атлады. Сары чәчләрен арттан кысып куйган, ялтырабрак торган алсу төстәге кыска халат кигән зифа гәүдәле бу ханым утыз биш яшьләр тирәсендә иде. Ул гәүдәсен туры тотып атлый, шунлыктанмы тулы тыгыз түшләре, адым саен ымсындыргыч бер көч белән уйнап алган очалары тагы да матуррак, назлырак булып тоела.

– Юк… – Ишек артындагы тавыш инде елауга охшый башлаган иде. – Юк… Булуы мөмкин түгел…

Хатын, адымнарын тизләтеп, бүлмә алдына килеп басты да ишекне этеп карады. Ул бикле иде. Хатын тагы бер омтылды да стена буенда торган кыңгырау төймәсенә басты. Эчтә ягымлы моңлы тавыш яңгырады. Тик шундук ирнең ыңгырашуы ишетелде.

– Юк… Юк… Юк…

Хатын бер мәлгә тынып торды. Ул ишек артында ниләр булганлыгын күз алдына китерергә тырыша сыман иде. Ләкин анда бернинди шау-шу да ишетелмәде, бары тик ир генә шыңшыды.

– Җаным! – дип, ишек артында эндәште хатын. – Ач әле…

Шыңшу тавышы бер мизгелгә тынып торды.

– Ишекне ач, кадерлем. Мин бу…

Җавап ишетелмәде.

Хатынның кайгыртучанлык белән мөлдерәмә тулы зәңгәр күзләрендә хәвеф өстенлек ала башлады. Тавышы да калтырангандай тоелды:

– Синең хәлең ничек анда? Җаным?!

Ишек артыннан беркем дә җавап бирмәде.

Бер гомергә тиң мизгел үтте.

Хатынның бөтен кыяфәтендә нидер үзгәрде, аның якты хисләр белән тулышкан гәүдәсе ничектер бушабрак, бөрешебрәк калгандай тоелды. Тулы иреннәрендәге алсулык югала төшкәндәй булды, күзләрендәге нурны зәңгәрсу томан алыштырды. Ул, хәлсез куллары белән ишек яңагына таянып, ишетелер-ишетелмәс пышылдады:

– Нәрсә булды сиңа… Җаным… – Һәм кинәт ниндидер ярсу белән ишекне төяргә тотынды, үзе бөтен өйне яңгыратып кычкырды: – Ник дәшмисең?! Нәрсә булды сиңа?! Нәрсә булды!

Кинәт ишек артында ниндидер кыштырдау ишетеп тынып калды. Ире, күрәсең, креслога утырып тынып калган җиреннән торып басты. Һәм, аягыннан да төшерми торган күн башмагын сөйрәп, бер-ике адым атлады. Хатын моны ишек аркылы үз күзләре белән күргән сыман булды. Бераздан ирнең бугазыннан ниндидер яман гырылдау сыгылып чыкты.

– Ю-у-уггк…

– Җаным! – Хатынның тавышында шатлыклы өмет ишетелде: – Ач әле ишекне…

Әмма аның сүзләре кинәт өзелеп калды. Ишек артында ирнең акылдан шашып кычкырганы барысын да күмеп китте:

– Юк! Моның булуы мөмкин түгел! Мөмкин түгел…

Һәм ишеккә нәрсәдер килеп бәрелде. Бу өстәл өстендә утырган бәллүр ваза булды шикелле. Челпәрәмә килеп ватылды… Әмма аның артыннан ук тагы нәрсәдер очты. Ишекнең теге ягындагы әйберләр, әле яңгыравыклы, әле тонык саңгырау авазлар чыгарып, бер-бер артлы ишеккә, стеналарга килеп бәрелә торды. Ахыр чиктә ир кулына эләккән бөтен нәрсәне кырып җимерергә тотынды. Урындыклар ауды, аның артыннан өстәл… Хатын инде ирнең эш бүлмәсендәге коточкыч тәртипсезлекне күз алдына китерә ала иде бугай. Тик ул моның өчен артык борчылмады. Тәртип урнаштыру кыен булмас. Бары тик ире генә исән-сау булсын. Бер-бер җиренә зәгыйфьлек кенә килмәсен. Соңгы арада үз-үзен аямыйча, төн йокыларын онытып эшләргә тотынды. Ул элек тә тик ята торган адәм түгел иде. Әмма ул чакларда дөнья җиткерү, тормышны көйләү өчен тырышты. Ә хәзер… Хәзер дөньялары җиткән иде инде, бераз ял итеп алса да буласы. Әмма ир элеккедән дә үҗәтрәк бер дәрт белән эшкә тотынды. Ул галим иде. Үз эшләре турында бик җентекләп сөйләргә яратмаса да, хатын аның ниндидер борынгы бер табылдык белән мәш килүен белә иде. «Бу минем тормышымда иң зур ачыш булачак, – дигән иде ире бер мәлне. – Әлеге табылдыкның серләрен ачсам, без тормышны бөтенләй башка үлчәмдә күрә башлаячакбыз!»

Һәм менә…

Әлеге ачыш кешелек өчен нинди генә зур казаныш булмасын, хатын иренең акылдан шашуын теләми иде. Ул бер мәлгә көтелмәгән хәлләрдән югалып калды. Аннан соң, тынычлана төшкәч, ишекне дөбердәтергә тотынды. Әмма моның бер файдасы да тимәячәген аңлап, кыңгырауга басты. Ягымлы тавыш ишетелде. Әмма ишекнең аръягындагы җәнҗал туктамады. Аның ире бу тавышны ишетми иде, ахры. Ишекне ачып кермичә, ирне тынычландырып булачак түгел иде. Хатын кичекмәс ярдәм хезмәтен чакырырга уйлап куйды. Һәм шундук колагында ышанычлы тыныч тавыш яңгырады.

– Мин сезне тыңлыйм…

«Юк… Мин болай гына…» Кичекмәс ярдәм хезмәтен чакырырга ярамый иде. Ире үз эшенең яшерен булуы турында берничә кат искәрткәне бар. Ишек артында нинди хәлләр булуы билгесез. Шуңа да «кичекмәс ярдәм» дигәнең мәңгелек зыянга әйләнергә дә мөмкин. Аны чакырырга ярамый иде. Нишләргә соң?

Ишекне ватарга кирәк. Хатын ашыгып баскычка юнәлде. Ишекләр белән идарә итү пульты подвалда иде. Баскычтан берничә адым атлау белән баягы ишекнең каләсе шалтыраган тавыш ишетелде. Хатын туктап калды. Ишек тоткасы кыбырдап куйды. Һәм хатын җиңел сулап кире борылды. Ул баскычтан менеп җитүгә, ишек ачылып китте. Бернинди тавышсыз гына ачылса да, ул ничектер шомлы булып тоелды. Хатын ниндидер куркыныч көтеп туктап калды. Ишек шар ачылды, бүлмә идәнендә кырылып яткан нәрсәләр шәйләнде. Әмма беркем дә чыкмады.

– Җаным… – Хатынның тавышында өмет тә, наз да, курку да бар иде: – Кадерлем…

Бераздан башмаклар шуышканы ишетелде. Һәм ишектә чәч-башы тузып, күлмәкләре ертылып беткән йолкыш ир күренде. Кырык яшьләр тирәсендә генә булса да, хәлсезләнеп бөкрәеп калганлыктан һәм үпкә чирле кеше шикелле еш-еш сулаганлыктан, ул бабайга охшап тора иде. Тартышып, җыерчыкланып беткән йөзе ул бабайны үтә дә карт итеп күрсәтә. Әмма хатынны иң борчуга салганы – ирнең күзләре иде. Ул күзләрдәге якты нур юкка чыккан, анда бары тик өметсезлек, салкынлык һәм үз хәлен җиңеләйтә алмауга үкенү ачысы гына. Тәненең бер генә җирендә кан әсәре күренмәсә дә, бу яралы ерткыч иде. Хатын куркудан артка чигенеп куйды. Ләкин шундук үзен кулга алып, елмайгандай итте.

– Нәрсә булды сиңа, кадерлем…

Хатынның тавышында өмет һәм кайгыртучанлык иде. Аның тавышындагы бу тойгылар мәңгелек туңлыкны да эретер сыман иде. Ләкин ир илтифат итмәде. Ул туң карашы белән тирә-якны күздән үткәрде. Һәм үз күзләренә үзе ышанырга теләмәгәндәй башын чайкап куйды.

– Юк… – дип пышылдады ул, – юк…

– Нәрсә булды, җаным?..

Ир шунда гына хатынга игътибар итте. Һәм дертләп китте. Бөтен йөзен тартыштырып, газап дулкыны үтте. Күзләре сагыш белән тулды.

– Якын килмә миңа! – дип җикерде ул кинәт кулларын алга сузып. – Якын киләсе булма!

Иренә таба бер адым атлаган хатын кинәт туктап калды.

Тынлык урнашты.

– Җаным…

– Дәшмә! – дип бүлдерде аны битараф тавыш. – Син чынбарлык түгел.

– Кадерлем…

– Дәшмә!

Хатын нидер әйтергә җыенган җиреннән тынып калды, сүзләренең өнсез дәвамы булып керфекләреннән ике тамчы яшь агып төште. Моны ир күреп калды.

– Синең күз яшьләрең дә чын түгел… – диде ул чиркангыч бер нәфрәт белән, – барысы да – иллюзия. Барысы да…

Хатын үзе дә сизмәстән артка чигенде. Ирнең кыяфәте юньлелек вәгъдә итми иде.

– Син миннән куркасың. – Ир кире каккысыз афәт сыман акрын гына хатынның өстенә килә башлады. – Куркуың да – чынбарлык түгел…

– Юк… – Хатын ирнең кулында ялтлап киткән нәрсәнең пычак икәнен аңлап, еламсырауга күчте. – Юк, җаным…

– Синең гомерең – чынбарлык түгел, – дип елмайды ир, – бары тик иллюзия генә.

– Юк, кадерлем… Кирәкми… – Хатын куркудан торып йөгермәкче иде, әмма кинәт аркасы белән стенага бәрелеп тынып калды. – Зинһар… Акылыңа кил…

– Мин акылымда… – Ир чынлап та акыллы кешегә охшап китте. – Һәм мин тормышның асылын беләм. Ә син белмисең…

Ир хатынын стенага кысрыклады да пычагын аның бугазына китерде.

– Бу пычак та – чынбарлык түгел. Мин менә синең муеныңа сызам… – Ир пычакны хатынның муенына җиңелчә генә ышкып алды, хатын дертләп куйды, сыгылып кына каны чыкты. Ир канны, бармагы белән сөртеп, хатынның ирененә тидерде. – Тәмләп кара әле… Чынлап та кан шикелле ул… Әмма ул кан түгел… Бу бары тик безнең күзебезгә генә күренә…

– Җаным… Кирәкми… – Хатын аның кулларын читкә этәрергә тырышты. – Кирәкми…

– Дәшмә! – Ир аны нык итеп стенага кысты да пычакны муенына аркылы терәде. Аз гына селкенсә дә, хатын суелачак иде. – Ләкин мин хәзер сине үтерәм икән, син чынлап та үләчәксең. Бу дөньяда үлем генә чын. Үлемнән башкасы – иллюзия.

Ир хатынның күзенә текәлде:

– Син мине аңлыйсыңмы?

Хатыны берни дип тә җавап бирә алмады. Ул акайган күзләре белән билгесезлеккә төбәлеп катып торуында булды. Ир аның муеныннан пычакны алды да сул кулы белән яңаклап җибәрде. Хатынның башы уң якка янтаеп китте. Йөзендә газапка охшаш нәрсә чагылып узды. Әмма шундук ул һушына килде, битенә кан йөгерде, күзләренә нур кайтты.

– Әйдә минем белән, – дип кабатлады ир, үзе, аның җавабын да көтмәстән арты белән борылып, эш бүлмәсенә атлады. Хатын аңа иярде. Ире аның котын алган иде. Бу адәм инде үзгәргән иде. Аның тагын нәрсә эшләргә мөмкин икәнен берничек тә алдан әйтеп булмый. Һәм аның зыян салмасына, хәтта үтереп ташламасына да ышанырлык түгел. Хатын ирнең арт чүмеченә карап шулай уйлады. Күңелендә калкып чыккан ниндидер хис уйдан эшкә күчәргә кирәклеген искәртеп ашыктырды. Ләкин пычаклы иргә ташлану җиңел нәрсә түгел. Хәтта аның артында торсаң да. Хәтта… Алда подвалга төшә торган баскыч… Менә шул урында тәвәккәлләргә мөмкин. Баскычтан көч белән этеп җибәрсәң, ул ярыйсы ук эштән чыгачак. Әмма баскыч янына җиткәч тә, хатын иренә ташланырга ашыкмады. Бу аның үз ире иде. Әле бернинди дә зыян салмады ич. Пычак тотса ни соң?.. Үтермәде бит… Ә үтерә алган булыр иде… Ир кинәт борылды да хатынының күзләренә карады. Аның күзләре адәмнекенә охшый башлаган иде инде. Һәм елмайгандай итеп куйды. Дәшмәде.

Бүлмәгә кергәч, ул тагын хатынына карап елмайгандай итте. Бу аның гафу үтенүе булды шикелле. Кыйратылган бүлмәдә исән-имин килеш калган бердәнбер шкаф шүрлегеннән ак пакет алып, хатынына күрсәтте.

– Менә…

Егермегә унбиш сантиметр чамасындагы бу пакетта теләсә нәрсә булырга мөмкин иде. Хатын берни дә аңламады.

– Нәрсә…

Ир сүзне нидән башларга белми аптырап торды. Хатыны аны гафу итмәгән иде, әлбәттә. Әмма ир үзенең ачышы турында кем беләндер уртаклашырга тели иде. Шунсыз булмый. Шунсыз ул акылдан шашачак.

– Менә шушы әйбер… борынгыдан калган мирас бу… һәм… Монда безнең дөньяның астын өскә китерерлек көч тупланган…

Кинәт сирена тавышы ишетелде. Ир сораулы карашын хатынына төбәде:

– Син?

– Юк… – Хатын сүзенең ышанычлы чыкмавын күреп, өстәп куйды: – Юк, мин чакырмадым. Ант итеп әйтәм, мин түгел…

– Һәй… – Ир тирән көрсенде дә кулындагы пакетны, ашыгып, шкафның бер тартмасына тыкты һәм аның ишегендәге төймәләргә баскалады. Эшен бетергәч, елмаеп куйды.

– Миннән китте, – диде ул үз вазифасын башкарып чыккан пәйгамбәр тынычлыгы белән. – Мин сине ярата идем, җаным. Барысы өчен дә рәхмәт сиңа…

– Нәрсә?! – Хатын үз колакларына үзе ышанырга теләмәде. – Нәрсә дисең?..

– Баш… – Ир баш бармагын маңгаена куйды. – Башымның бер исән урыны да калмасын… Син аңладыңмы?

Хатын аңламады. Сирена тавышы хәзер колак төбендә генә ишетелә башлады. Бераздан ишек кыңгыравы шылтырады.

– Аларны мин чакырмадым, – диде хатын, акланырга теләп. – Мин чакырмадым…

– Беләм… – Ир елмайды. – Алар үзләре минем эзгә төшкән… Без туктаусыз күзәтү астында… Шуңа күрә баш турында онытма… Хәер… Бар, ишекне ач…

Инде ишекне нык итеп дөбердәтәләр иде.

– Бар, – дип кабатлады ир, – керсеннәр.

Хатын коридорга атлады. Тик шундук нindidер шартлау ишетелде. Ишекне җимереп кергән тәртип сакчылары инде коридор буйлап йөгерешә иде.

– Бар, – дип ашыктырды ир, – каршы ал…

Аның тавышында кырыс таләпчәнлек бар иде, хатын тәртип сакчыларына каршы атлады. Ләкин шундук артында шартлау тавышы яңгырады. Ул кинәт борылды һәм үз күзләренә үзе ышана алмыйча катып калды. Иренең башы торган урында куе төтен генә иде. Бераздан төтен таралды һәм… Ирнең муенында, ике якка караган кушуч сыман, яңак сөякләре генә серәеп тора иде. Башы тулысы белән диярлек юкка чыккан. Куе кан, баш мие һәм тагын әллә нәрсәләр, бергә укмашып, тәрәзә пәрдәләренә, шкаф ишегенә, идәндә аунап яткан чүп-чар өсләренә чәчрәгән. Ирнең гәүдәсе беркадәр аягында баскан килеш торды да акрын гына чалкан ава башлады. Хатын, әлеге коточкыч күренештән качарга теләп, күзләрен йомды. Әмма шундук тамагына төер килеп тыгылды, һәм ул укшып идәнгә бөгелеп төште.

Тавышка йөгерешеп килеп җиткән тәртип сакчылары коралларын ирнең үле гәүдәсенә һәм хатынга төбәп тынып калдылар. Бераздан калын гәүдәле озын ир алгарак чыкты да хатынга иелде. Һәм, кабат күтәрелеп, иптәшләренә ымлады. Ике егет, хатынны күтәреп алып, бүлмәдән чыгып киттеләр.

– Нәрсә эзләргә кирәген беләсез, – диде баягы ир калганнарга, – ул шушы бүлмәдә булырга тиеш. Тапмыйча туктамагыз.

Һәм баягы ике егет артыннан иярде. Тегеләр, арттан начальниклары атлаганны күреп, бер мәлгә туктап калдылар.

– Тикшерүләр үзәгенә илтергә, – диде ир, алар янында адымын да акрынайтып тормастан, – яхшылап эшкәртергә һәм юк итәргә.

Һәм ишеккә юнәлде. Әмма җиде-сигез адым атлауга ук, артында нindidер шартлау ишетеп борылырга мәҗбүр булды. Һәм сүгенеп куйды. Ике тәртип сакчысы да гаҗәпләнүнең чигенә җитеп катып калган иде. Алар битләренә, киемнәренә чәчрәгән канлы ит кисәкләрен дә сизмиләр, ахры. Ә галимнең хатыны идәнгә сузылып төшкән… Аның башы юк иде…

– Тегеләргә кушылыгыз! – дип боерды ир. – Аңлашыламы?!

Егетләр бераз аптырап тордылар да ашыгып бүлмәгә кереп киттеләр.

Ир урамга чыкты. Тирә-ягына каранып, бертын басып торды.

– Юдыртыгыз барысын да… – диде аннан соң.

Аның тирә-ягында берәү дә юк, кемгә эндәшкәнен дә аңларлык түгел иде.

**2**

Юк, моның чынбарлык икәненә ышанырлык түгел иде. Әгәр берничә көн элек кенә берәрсе шушы хакта сөйләсә, Ләйлә аны акылдан шашканга исәпләр, һичьюгы, бик оста ялганчы дип атар, теләсә нәрсә эшләр, әмма аның сүзләренә бер тамчы да ышанмас иде. Хәтта әле дә, барысын да үзе күреп, үзе кичергәндә дә, бу күренешнең төш кенә түгелме икәненә шикләнеп куйды.

Уянганда ук, Ләйлә ниндидер якты хисләр белән, үзен бик яхшы һәм көчле итеп тоеп уянды. Аягына басуга ук, иңенә назлы бәрхет халат ябылды, аякларына йомшак башмак киелде… Әле менә ваннада…

Ваннага килеп керү белән, бүлмә эче хуш исләр белән тулды, якты моң агыла башлады. Стеналар бер мизгелгә генә сыекланып алды да анда, сафтан-саф сулы елга хасил булды. Елга ярындагы талларда кошлар сайрый, яфракларны җиңелчә генә тибрәндереп, ягымлы җил исә. Сулар һавасы да саф, татлы – бөтен булмышыңа үтеп керә, күңелгә чиксез ләззәт бирә. Ләйлә су керү турында уйлауга ук, өстендәге киемнәре юкка чыкты, һәм ул, аяк астындагы кайнар комга басып, елгага атлады. Аяк йөзеннән суга кергәч, иелеп, учлары белән җылы дулкыннарны сөзде, битләрен чайкап алды, аннан соң муеннарын, кулбашларын сыпырды да бар күңелен биләп алган тилерткеч дәрт белән елга куенына ташланды. Төрле төстәге вак балыклар, аннан өркеп, читкә тайпылышты. Ләйлә аларга игътибар итеп тормады, колачын җәеп йөзәргә тотынды. Ул, ләззәткә бирелеп, елганың бер ярыннан икенчесенә йөзеп уйнады да, аз гына арыганлыгын тоеп, дулкыннар өстендә чалкан әйләнде. Шул халәтендә, кояшның назлы нурларыннан күзләрен кыса биреп, татлы елмайды, кулларын җәйде. Ул болай да су коенырга, су коенганда дулкыннар өстендә менә шулай чалкан ятарга ярата иде. Әмма бу юлы елганың дулкыннары гади түгел иде. Алар хатынның аркаларына, ботларына, бөтен тәненә әйтеп аңлатып булмаслык рәхәтлек биреп массаж ясадылар. Беркадәр шулай яткач, ул, рәхәтлеккә түзәлмичә, суга чумды. Башта гадәтенчә күзләрен йомса да, соңрак, үзенең кайда икәнлеген искә алып, тирә-ягына күз салды һәм сокланудан чак кычкырып җибәрмәде. Монда оҗмах хозурлыгы иде. Саф чиста су. Кояш нурында төрле төсләргә кереп, мәрҗәндәй ялтырап китүче эреле-ваклы гүзәл балыклар, әллә нинди сихри үсемлекләр…

«Илдар белән бергә керергә кирәк булыр, – дип уйлап алды хатын, – монда шундый соклангыч икән…»

Ире исенә төшүгә, ул кабат дулкыннар өстенә чыкты да яр буена йөзеп китте. Суның муен тиңентен урынына җиткәч, басып калды. «Чистарынырга кирәк», – дип уйлады. Шул арада ниндидер күзгә күренмәс кул аны хуш ис бөркеп торган назлы мунчала белән юарга кереште. Бу кызык та, рәхәт тә иде. Бераздан юу тукталды, Ләйлә тагы бер кат суга чумып алды. Дулкыннар өстенә таралган күбекләр юкка чыкты…

Тагы бер мизгел үтүгә, ул ванна бүлмәсендә иде инде. Бүлмәдәге җылы дулкын аның тәнен киптерде, чәчләрен матурлап тарады. Бераздан хатынның өстендә алсу төстәге кыска халат, аякларында йомшак башмак пәйда булды. Ул, боларны күреп, канәгать елмаеп куйды һәм, ваннадан чыгып, кухняга юнәлде. Бөтен бүлмәгә тәмле аш исе таралган иде.

– Илдар! – дип дәште хатын. – Ашарга әзер…

Ире, канәгать елмаеп, ишектә пәйда булды. Ул да яңа гына ваннадан чыккан иде. Хатыны янына килеп, аның бит очыннан гына үбеп алды да табынга утырды. Өстәл буп-буш иде. Алар утыруга ук, алларында берешәр стакан алма суты пәйда булды. Аны эчеп куюга, буш стаканнар юкка чыкты да, тәлинкәләр барлыкка килде…

Ир белән хатын бер-берсенә карап елмаешып тордылар да кашыкка үрелделәр.

– О! Соклангыч! – диде ир пылауны тәмләп карау белән. – Мин синең нәкъ шундый итеп пешергәнеңне яратам.

Ләйлә кеткелдәп куйды.

– Әмма монысын мин пешермәдем, – диде ул, бераз сагая төшеп, – моны йорт пешерде.

– Әмма ул аны нәкъ синеңчә итеп, мин яратканча итеп пешергән. Менә үзең дә ашап кара әле.

Хатын бер кашык капты да иренә карады.

– Нәрсә?! – диде ир, аның кыяфәтеннән сагаеп. – Нәрсә булды?

Хатын елмайды.

– Әмма бу… Хәтереңдәме, син бермәлне, мин эштән кайтуга, пылау пешереп куйган идең? – диде хатын канәгать бер хыялыйлык белән. – Мин аны шултиклем нык яраткан идем… Бу – нәкъ шул пылау… Бу мин пешергәнчә түгел…

Ир тәлинкәгә үрелгән җиреннән туктап калды.

– Ләкин… – Һәм ул, елмаеп, хатынының тәлинкәсеннән бер кашык алып капты. – Чынлап та! Минекен дә тәмләп кара әле.

Хатын ирнең тәлинкәсенә үрелде дә шаркылдап көлеп җибәрде:

– Мин сиңа ышанам! Ышанам. Өй безгә үзебез яраткан ашны пешерә. Миңа мин теләгәнчә итеп, сиңа – син теләгәнчә. Менә могҗиза!

– Соклангыч!

Һәм алар сөенеч белән ашарга керештеләр.

Бу өйгә алар әле кичә генә күченеп килгәннәр иде. Бүген беренче көнне генә каршы алалар. Һәм һәр күренеш алар өчен зур яңалык, чиксез могҗиза булып тоела иде. Алар бәхетле иделәр. Бер-берсен өзелеп яраткан утыз биш яшьлек ир белән хатын өчен шуннан да зуррак бәхет юктыр төсле иде.

Бераздан Ләйлә ирен озатырга ишек төбенә чыкты.

Икесеннән дә якты нур тарала иде. Өйдә бары тик алар гына тоя, алар гына ишетә алган татлы моң яңгырый.

– Мин мондый йорт турында хыяллана да алмаган идем… – Хатын, назланып, аның муеныннан кочаклады: – Рәхмәт сиңа, кадерлем!

Илдар канәгать елмайды. Хатынының чәчләреннән сыйпап, бит очыннан үбеп алды да аның кулын сак кына шудырып төшерде.

– Чынлап та шәп, әйеме? – диде ул, галстугын төзәтеп. – Кыйбат та түгел.

– Ә миңа, барысыннан да бигрәк, диван ошады, – дип, назлы елмайды хатын. – Эшеңнән тизрәк урап кайт, яме…

Илдар сәгатенә карап алды да, мут елмаеп, тагын галстугына үрелде.

– Әле вакыт бар. – Ул, галстугын салып, шкаф ягына ыргытты. – Күп түгел түгелен…

– Юк… – Ләйлә аның галстугын эләктереп алды да кабат иренең муенына кидерде. – Эштән кайткач, яме…

Илдар иренен бүлтәйтеп куйды. Һәм бик төксе кыяфәт белән галстугын төзәтергә тотынды.

– Эшеңә соңлавыңны теләмим, – дип акланды хатыны, – үзең беләсең бит инде, мин ашык-пошык кыланганны яратмыйм. Кайткач, яме… Иркенләп, рәхәтләнеп…

Илдар аны кинәт кочаклап алды да, күкрәгенә кысып, кая туры килә, шуннан үбәргә тотынды.

– Бердәнберем минем…

– Җаным…

Алар, үзләре дә сизмәстән, наз дөньясына чумдылар, һәм кайнар сулышлар моңы, хисләр яктылыгы бөтен өйгә таралгандай булды. Әлеге иркәләшү тиз генә тукталачак түгел иде. Әмма көтмәгәндә ягымлы тавыш ишетелде:

– Онытылып китмәгез! Илдар, эшеңә соңлыйсың.

Әлеге тавыштан икесе дә аптырап катып калдылар. Кемнедер күрергә теләгәндәй, ирексездән тирә-якка күз ташладылар. Һәм эшнең нәрсәдә икәнен аңлап, икесе дә берьюлы кычкырып көләргә тотындылар.

– Өй! – дип шаркылдады Ләйлә. – Өй безгә рөхсәт итми.

– Күралмыйм бу өйне! – дип көлде Илдар. – Аның безгә комачауларга ни хакы бар? Ишетәсеңме, өй, син безгә комачаулама! Югыйсә…

– Ә ул чынлап та хаклы… – диде Ләйлә. – Сиңа китәргә вакыт, кадерлем…

Илдар хатынын үпте дә ишек төбендәге кечкенә келәмгә барып басты. Шундук келәм эченнән аның туфлие күренде, ул үзлегеннән ирнең аягына киелде. Бу хәл мизгел эчендә эшләнде, хәтта күз дә иярерлек булмады. Бер үк вакытта ниндидер күзгә күренмәс кул Илдарның чәчләрен матурлады, киемнәрен төзәтте, хәтта хушбуй да сиптереп куйды. Һәм барысы да әзер булгач, ишек ачылды.

– Хәерле юл сиңа, Илдар! – диде ниндидер ягымлы тавыш. – Исән-имин йөреп кайт…

Боларны сокланып күзәтеп торган Ләйләнең иренендәге елмаю бер генә мәлгә сүрелеп калды. Ишектән чыгып киткәндә, иренә соңгы сүзне ул әйтергә тиеш иде. Ә монда… Адәм баласының бөтен теләк-хаҗәтләрен үти торган шушы йорт хатынны икенче планга күчереп куяр төслерәк тоелды. Ләкин ул моңсулыкка бирелмәскә тырышты. Йорт чынлап та соклангыч иде. Ул сине үзе ашата, үзе киендерә, үзе йоклата. Йокы турында уйлауга, ул бүгенге төнне исенә төшерде дә татлы елмаеп куйды. Диван. Ир белән хатынның психологик һәм физиологик үзенчәлекләрен искә алып эшләнгән бу диван йокының тирән һәм тәмле булуын гына тәэмин итми, ул хәтта җенси мөнәсәбәтләрне дә тулыландырырга, яктырак, татлырак, ләззәтлерәк итәргә сәләтле иде. Гомумән, бу йорт кеше өчен, аның бәхетле тормышы өчен эшләнгән изге нәрсә иде.

Ләйлә болдырга йөгереп чыкты. Илдар машинага утырып өлгермәгән иде әле. Ул хатынын күреп елмайды. Ләйлә бармакларын елмаюлы иренәнә тидереп алды да иренә кул болгады. Илдар аңа карап күз кысты һәм кабинага кереп утырды. Машина кузгалып китте.

**3**

– Мин сезгә хезмәт итәргә әзер, – дигән ягымлы тавыш ишетелде машина кәнәфиенә кереп утыру белән. – Кая юнәләбез?

– Эшкә.

Илдар машинаның мондый гадәтләренә күнегеп беткән иде инде, артык әһәмият бирмәде. Ул йорт турында уйлады. Һәм болдырга чыгып кул болгап калган хатыны турында. Әле аерылышуларына мизгел дә үтмәде, ә ул инде сагынып та өлгерде. Сагыну көчле иде. Өйдән ераклашкан саен, йөрәгенең ниндидер бер кылы ныграк суырылган төсле тоелды. Кире борыласы, эшкә барудан берәр сәбәп табып баш тартасы иде. Мондый гамәл ахмаклык икәнен белсә дә, ул бүген беренче тапкыр өйдән китәргә теләмәде. Беренче тапкыр ул чынлап, өзелеп сагынды. Сагыну көчле иде. Тик ул бер нәрсәне генә ачыклый алмады. Ләйләне сагынуы идеме, әллә өйнеме? Икесен дә… Икесен дә сагыну иде бу… Һәрхәлдә, Илдар шулай уйлады, үзен шуңа ышандырырга тырышты…

Илдар тәрәзәгә карап бара башлады. Иртә иде әле, кояш офык читендә генә тора, ә һавада төнге салкынлык таралып өлгермәгән иде, урамда кеше заты күренмәде. Хәер, Уфаның бу бистәсендә җәяүлеләрне бик күпләп очратырмын димә. Бу – йокы районы. Кешеләр иртә белән эшкә чыгып китәләр дә монда кичен генә кайталар. Ә өйдә калучылар булса, алар урам буенда селкенеп йөрми. Өйләрендә бөтен нәрсә өчен дә шартлар тудырылган, өйләрендә алар оҗмахтагы шикелле яшиләр. Кеше-фәлән күренмәде. Ә урамнар… Күз явын алырлык якты нурлар белән балкып торган йортлар да, ул йортларны әйләндереп алган коймалар да искиткеч дәрәҗәдәге сәнгать әсәренә тиң иде, алар тередер, сулыш алалардыр, тирә-юньдәге хуш исләрне тоялардыр, талгын гына агылган тылсымлы моңны ишетәләрдер шикелле иде. Хәтта автомобиль юлы да җанлыдыр, син юл буйлап бармыйсыңдыр, урыныңда гына торасыңдыр, юл сине каядыр йөздереп барадыр сыман тоела иде. Соклангыч матурлык монда һәммәсен дә җанлы итеп күрсәтә, ә җаны бар әйберләргә карата ирексездән күңелдә хөрмәт уяна, син аларны үзең дә абайламастан ярата башлыйсың. Илдар ирексездән рәхәт елмаеп куйды. Бу дөньяны ул ярата иде. Һәрнәрсәсен аерым-аерым һәм барысын берьюлы. Үзең яшәгән дөньяга сөю йөртү шултиклем рәхәт иде.

Агыйдел күперен чыгып Зорге урамына якынлашуга, хәрәкәт арта төште. Юлда автомобильләр дә, тротуардан атлаган кешеләр дә ешайды. Монда бөтен нәрсә үзгә иде. Бу инде

алар яшәгән бистә түгел, бу шәһәрнең үзәгенә керә. Һәм ике-өч катлы шәхси йортлар бөтенләй юк, алар урынында егермешәр катлы хөкүмәт өйләре иде. Әмма алар да Илдарның күңелендә уянган ярату хисен сүрелдерә алмады. Бу йортлар үзләренчә матур иде. Алар да иртәнге кояш нурында төрле төсләргә кереп балкый, алар да җиргә үзләренчә ягымлы нур сибә. Моннан берничә көн элек кенә Илдар белән Ләйлә дә шушы йортларның берсендә яшиләр иде. Илдар үзләренең шушы йортларда гомер иткән чагын күз алдына китерергә тырышты. Унтугызынчы катта урнашкан өч бүлмәле фатир иде ул… Гаҗәпкә каршы, шуннан артык берни дә килеп чыкмады. Хәтерли алмады. Бөтен уңайлыклары булган яңа өйләренә кичә генә күченеп килсәләр дә, Илдар фатирдагы тормышның нечкәлекләрен оныткан иде. Әмма ул бер нәрсәне яхшы белә, бу фатирлардагы тормыш һич тә зарланырлык түгел, гомумән, алар бәхетле илдә, бәхетле шәһәрдә яшиләр, һәм алар белгән бөтен кеше дә үзен бәхетле итеп тоя иде.

– Эх!..

Илдарның күкрәгеннән ургылып чыккан шушы канәгатьлек авазыннан якты моң яралды, һәм ул моң, бар тирә-юньне дәртле дулкынга күмеп, бөтен салонга яңгырады. Ир аны ләззәтләнеп, бөтен күзәнәкләренең рәхәт зембērләвен тоеп тыңлады. Үз күңеленнән ялган моң ич! Әлбәттә, Илдар әлеге моңның автомобиль синтезаторыннан таралуын яхшы белә иде. Аның күңел кичерешләрен тоеп торган автомобиль шул халәтенә туры килердәй музыка уйната. Ләкин бу үзе үк соклангыч түгелмени!

Бераздан өен һәм хатынын юксыну белән бәйле баягы уңайсызлыкның эзе дә калмады. Ул үзен бәхетле итеп сизде. Шатлык очкыннары уйнатып торган күзләре белән тәрәзәгә бакты. Бәхетле шәһәрнең якты урамына. Урамда кешеләр бик күп түгел иде. Дөресрәге, нәрсә турындадыр сабыр гына гәпләшеп килгән ике ирдән башка берәү дә күренмәде. Ирләрнең икесе дә кырык яшьләр тирәсендә булып, икесе дә костюм-галстуктан иде. Хәтта киемнәренең тегелеше дә бертөрле сыман тоелды. Алар бары тик төсләре белән генә аерылалар, бөдрә коңгырт чәчлесе ак күлмәге өстеннән көрәнсурак төстәге пинжәк кигән, ә җирән чәчләрен кыска итеп алдырганында кара зәңгәр пинжәк иде. Болар, күрәсең, якындагы берәр урында эшләүче инженерлардыр, өйләре якын булгач, эшкә дә җәяүләп кенә йөриләрдер. Илдар елмаеп куйды. Саф һавалы якты урамнардан җәяү атлауның да үз рәхәтлекләре бар. Кинәт аның елмаюы бер мизгелгә катып калды. Күзләрендә гаҗәпләнү галәмәте пәйда булды. Илдар башын селкеп, керфекләрен җемелдәтеп алды да тәрәзәгә ныграк сыенды. Күзләре аны алдамый иде бугай. Көрәнсу пинжәк кигән ир юкка чыккан иде. Ләкин моның булуы мөмкин түгел. Урамнан атлап барган җиреннән адәм баласы берничек тә эзсез-нисез юкка чыга алмый. Әллә күзенә генә күрендеме соң? Автомобиль әлеге күренешне узып киткән иде инде. Илдар артына борылып-борылып карады. Мөгаен, күзенә генә күренгәндер, әнә ич, бергә атлап барган иптәше берни булмагандай юлын дәвам итә. Янындагы кеше кинәт юкка чыкса, алай тыныч кала алмас иден. Димәк, күзгә генә күренгән. Илдар үзенең сәерлеге турында уйлап елмаеп куйды. Тулысынча сау-сәламәт кеше булса да, кайчагында аның белән мондый кыска вакытлы гаҗәп күренешләр булгалаштыра иде. Докторлар да артык әһәмият бирми, күрәсең, бик зарарлы нәрсә түгел. Үз уйларыннан үзе юанып, ул якты ягымлылык белән яңгыраган музыкага колак салды. Әллә нинди илаһи моң! Җанны иркәли торган…

Беркадәр вакыттан музыка талгын гына үзгәрә төште, һәм Илдарның уйлары эш урынына күчте. Ул бүген башкарырга тиешле кичектергесез эшләрен барлады, һәм тизрәк офиска барып, аларны тормышка ашыру теләге уянды.

Ул Фәннәр академиясенең өлкән гыйльми хезмәткәре иде. Рәсми телдә шулай атала, ә асылда алар бүлектә нибары дүрт кенә кеше: бүлек мөдире профессор Рамил Әхмәтов, озын буйлы, таза гәүдәле, иллегә җитеп килүче ир, аның урынбасары Илдус һәм бөтен нәрсәгә дә өлгерә торган кечкенә буйлы ябык кыз Зифа. Әлбәттә, килеп-китеп хезмәттәшлек итүче, теге яки бу мәсьәләдә фикер алышучы, киңәш бирүче галимнәр аз түгел, әмма нигездә төп эшне

шушы дүртәү алып бара, төрле тәҗрибәләр үткәрәләр, исәп-хисаплар ясыйлар, көнозын бергә кайнашсалар да, бер-берсенең хәлен белешергә дә вакыт табалмаган чаклары да бик еш була.

Әле алар ясалма кан эшкәртү белән мәшгуль иделәр. Бу кеше организмын теләсә нинди халәттә дә кислород белән тәэмин итүче кан булырга тиеш. Әгәр барысы да уңышлы килеп чыга икән, кеше, су астында да үзен иркен хис итеп, үзе теләгән кадәр сәяхәт кыла алачак. Әлбәттә, барысы да яхшы булачагына аларның ышанычы зур иде…

– Без билгеләнгән урынга килеп җиттек, – дигән ягымлы тавыш ишетелде. – Сезнең күрсәтмәләрне көтәм…

Илдар уйга бирелгән иде, әлеге тавышның каян килүен башта аңламыйчарак торды. Аннан соң елмаеп куйды.

– Рәхмәт! – диде ул, аппаратуралар панелен сыйпап. – Рәхмәт сиңа… Әлегә беркая да китмибез. Үз урыныңа барып ял итәрсең…

Һәм урамга чыкты. Автомобиль ниндидер якты нур белән балкып алды да акрын гына стоянкага юнәлде. Илдар аның артыннан бертын карап торды. Һәм Академиягә илтүче эскалаторга басты.

**4**

Бүген дә эш тыгыз иде. Килү белән, барысы да бер-ике авыз сүз генә алыштылар да тәҗрибә үткәрергә әзерләнә башладылар.

Перфторуглеродларның, икенче төрле әйткәндә, барлык углерод бәйләнешләре фтор ионнары белән тулыландырылган углеводородларның, кеше организмындагы бернинди матдә белән дә бәйләнешкә кермәве моннан берничә гасыр элек үк билгеле булган. Бу – кешенең аерым бер органын кирәкле матдә, әйтик кислород белән тиешле дәрәҗәдә тәэмин итүгә юл ача. Бүгенге тәҗрибәнең нигезендә шушы гади күренеш ята иде.

Ләкин профессорның исәп-хисаплары бик тә үзенчәлекле була, һәм ул алар белән артык уртаклашып бармый иде. Бүлектә эшләгән галимнәрнең һәрберсе мәсьәләнең үзенә кагылган өлешен генә яхшы белә, ул шуны зур төгәллек белән башкарырга тиеш. Гомумкартинаны бары тик профессор үзе генә күзаллый ала. Һәм тиешле нәтиҗәне дә фәкать ул гына чыгара. Бу, әлбәттә, галимнәрнең эчен пошырмый калмый, әмма фән дөньясының тәртибе шулай: кем башлангычында эшлисең, шуның әмерен үтәргә тиешсең. Әгәр буйсынырга теләмисең икән, үз эшеңне булдыр. Ә Рамил Әхмәтович белән эшләү – үзе бер бәхет. Ул җитди галим. Яхшы кеше. Бу ике сыйфатны бер галимдә сирәк очратасың. Илдар үзен бик зур химикка исәпләми, мәсәлән. Монда ул очраклы кеше. Үз башлангычында ниндидер яңа ачышлар ясарга теләге дә, мөмкинлеге дә юк. Кайчагында ул үзенең ник монда эшләп йөрүенә аптырап та куя. Ләкин нишлисең, кайда да булса хезмәт түгәргә кирәк. Ә Фәннәр академиясе – начар урын түгел… Кыскасы, хәлләрнең әлеге торышы Илдарны артык борчымый иде. Ул үзенең вазифасыннан да, хезмәттәшләреннән дә, эш хакыннан да канәгать. Шуңа да һәрнәрсәне җитди итеп, бернинди ялгышларга да урын калдырмаслык итеп башкарырга тырышты. Барысы да аның хәлендә иделәр бугай, берәү дә игътибарын читкә юнәлтмәде.

Бары тик төш җиткәч кенә, алар, эшләрен читкә алып куеп, башларын күтәрделәр һәм шунда гына бер-берсен күргән сыман булдылар.

– Ничек соң яңа йортта? – дип, мыек астыннан елмайды Илдус. – Рәхәтме?

– Соклангыч! – Илдар да елмайды. – Әйтеп бетермәле түгел…

– Ә сезгә кадәр анда кем яшәгәнен беләсеңме соң?

– Юк. Ә кем яшәгән?

– Профессор Гаскәров. Хатыны белән.

– Нәрсә?!

– Илдус! – Рамил Әхмәтовичның тавышында шелтә яңгырады. – Теләсә нәрсә сөйләп, кешенең кәефен җибәрмә. Тиздән син дә шундый ук йортларның берсенә урнашачаксың.

– Ә профессор Гаскәров кем ул?

Илдус аның шуны да белмәвенә авыз ерды. Рамил Әхмәтович җитди иде.

– Бик талантлы бер галим бар иде, – диде ул, – әмма соңгы вакытларда күренми башлады. Аны акылын җуйган икән дип сөйлиләр. Хатынын да, үзен дә психик авырулар хастаханәсенә салганнар.

– Ә йортын сиңа бирделәр, – дип чеметеп алды Илдус. – Шәп бит!

– Илдус! – Бу юлы профессорның тавышы кискен яңгырады. – Җитте!

– Чынлап та шулаймыни? – Илдар профессорга карады. – Без аның йортында яшибезме?

– Әйе. – Рамил Әхмәтовичның тавышы тыныч иде. – Сез аның йортында яшисез. Ләкин йорт инде сезнең психологик хәлегезгә, сезнең хасиятләргә яраклаштырылган. Ул сезнеке.

– Ә профессор Гаскәров… – Илдар тотлыгыбрак калды. – Ул дәваланып чыккач… Әйе, ул дәваланып чыккач, безне тагын күчерәчәкләрме?

– Юк. Үзегез теләмисез икән, сезне беркем дә беркая да күчермәячәк.

Илдар елмаеп куйды. Әмма аның елмаюы Илдуска ошамады.

– Ләкин сез үзегез үк күчәргә теләячәксез, – дип, астыртын елмайды ул. – Син үзең күчәргә теләячәксең. Чөнки син минем чиратка кердең. Ул йорт миңа булырга тиеш иде.

– Нинди аерма?! – дип елмайды Илдар. – Мин кичә күчтем, син иртәгә күчәчәксең…

Һәм, үзенең артыгын ычкындырганын сизеп, кинәт туктап калды.

– Иртәгә?! – Илдус үз колакларына ышанырга теләмичә, әле Илдарга, әле Рамил Әхмәтовичка карады. – Ничек иртәгә?

Кинәт бүлмә ишеге ачылып китте дә Зифаның елмаюлы йөзе күренде

– Ә менә шулай! – диде ул, кулындагы пультны Илдусның борын төбенә сузып. – Сөенчегә нәрсә бирәсең?

Илдус аптырап торуында булды.

– Пульт! – диде ул ниһаять, елмаеп. – Фатир белән идарә итү пульты!

– Сөенчегә нәрсә бирәсең? – дип кабатлады Зифа. – Әйдә, саранланма…

– Бүген мин сыйлыйм! – Илдус кызның кулыннан пультны эләктереп алды. – Барыгызны да! Киттек хәзер үк ресторанга!

– Ашыкма әле син, – дип елмайды Рамил Әхмәтович, – эшне ташларга уйлыйсыңмы әллә?

– Ә бәлки, иртәгәгә калдырырбыз?

Рамил Әхмәтович кеткелдәп көлеп җибәрде:

– Ә бәлки, фатирга күченүеңне кичектереп торырбыз?

– Юк инде, Рамил Әхмәтович! – Илдус бәхетле иде. – Бер минутка да кичектерү юк! Ә табынны… Эштән соң… Эштән соң барыгызны да гаиләләрегез белән бәйрәм табынына чакырам…

– Ашыкма әле, Илдус, – дип елмайды Рамил Әхмәтович, – ашыктырма. Бүгенгә табынны кичектереп торырга туры киләчәк. Син башта кайтып хатыныңны сөендер. Ә иртәгә… Иртәгә безне дәшәрсең… Иртәгә мөмкин. Ә бүген булмый.

– Миңа гел көтәргә язгандыр инде, – дип үпкәләгәндәй итте Илдус, – гел көтәргә…

– Син үзең ашыгасың, – дип елмайды Зифа. – Ә ашыккан кеше ул гел көтәргә мәҗбүр була.

– Ярый, – дип елмайды Илдус, – иртәгә икән – иртәгә!

– Юк, бүген дә! – дип кеткелдәде профессор: – Төшке аш – синең исәптән. Бәйрәмне бүген башлыйбыз…

– Иртәгә дәвам итәбез… – дип элеп алды Илдар.

– Берәр айдан туктыйбыз, – дип шаркылдады Зифа. – Ай буе синең яңа фатирны бәйрәм итәбез.

– Юк, алай булмый! – Илдус, ике кулын да күтәреп, аларга каршы төште. – Илдарның йортын кем юа?!

– Ну, аныкы бик һуш китмәле түгел бит инде… – диде профессор, мыек астыннан елмаеп. – Чирле кешеләрдән калган бичара гына өйне юдың ни, юмадың ни аны… Ә синеке!.. Монысы бөтенләй бүтән!

– Ярый, килештердегез! Киттек, әйдә, ашханәгә!..

Алар шулай, шау-гөр килеп, ашханәгә атладылар. Ашханә дигәне лабораториядән чыгып берничә адымда гына урнашкан бер бүлмә иде. Бу – аларның гына ашау-эчү урыны, башка бүлекләрнең һәркайсының үзенеке бар, һәм анда да күзгә күренмәс роботлар синң теләгән ризыгыңны әзерләп бирә. Һәм, әлбәттә, монда барысы да бушлай, ә Илдусның «минем исәп, синең исәп» дип сөйләнүләре бары тик күңел күтәрү өчен генә, һәм моны бөтенесе дә аңлый иде.

– Ике бифштекс, бер балык, бер… – дип тезеп китте Илдус, әмма профессорның күтәрелгән кулларын күреп туктап калды. – Тагы көтәр-гәме?

– Юк, – дип елмайды Рамил Әхмәтович, – Илдар белән безгә – ике бокал минераль су. Ә үзегезгә теләгәнчә алыгыз.

– Ләкин, профессор…

– Без бүген синең белән – тәҗрибә астында булачак кешеләр, – дип бүлдерде аны Рамил Әхмәтович. – Шуңа күрә тамак ягын бераз чикләргә туры киләчәк.

Илдар бер сүз дә әйтмәде, өстәлдә пәйда булган тәлинкәләргә карап, моңсу елмаеп кына куйды.

**5**

Илдар киткәч, Ләйлә күтәрмәдә озак кына басып торды. Күршедәге йортларны күзәтте – соклангыч матур йортлар, әмма карашың тоткарланырлык бер генә нәрсәсе дә юк. Ул үзләренең өенә гашыйк, шуңа да башкаларга бик игътибар бирми иде бугай. Акрын гына күтәрмәдән төшеп, ихата буйлап атлады. Койма буйларындагы чәчәкләр дә, сукмак янындагы куаклар да искиткеч бер төгәллек белән утыртылган – Ләйлә бер мәлгә моның адәм кулы белән эшләнүенә шикләнеп тә куйды. Һәм елмайды. Әлбәттә, кеше кулы белән түгелдер. Күзгә күренмәс роботлар сине тирбәтеп йоклата, тәмләп ашата, хәтта аягыңа башмакка кадәр кидерә икән, урамдагы эшләр, әлбәттә, адәм кулы белән башкарылмый инде. Элеккеге фатирларында Ләйлә бөтен эшне диярлек үзе эшли иде. Кер дә юа, ашарга да пешерә… Әлбәттә, боларның барысын да кечкенә роботлар башкара инде, әмма алар белән Ләйлә идарә итә иде. Әле ул үзен ничектер читкә тибелгәндәйрәк итеп тойды. Ул үз өендә түгелдер, кунакка гына килгәндер шикелле булды. Үзенең хуҗа икәнен расларга теләп, бәйләнерлек урын эзләп, ары-бире йөренде дә кире болдырга килеп басты.

Өйгә керәсе килми иде.

Ул янә буш урамга күз йөгертеп алды. Күршеләрдә кемнәр яши икән? Моны ул тиз генә белә алмас инде. Шәһәр җирендә күрше белән күрше бик аралашып яшәми. Унар ел бер тирәдә гомер итеп тә, кемнең кем икәнен белмәгәннәр күп. Кинәт Ләйлә үзен япа-ялгыз итеп тойды. Илдар ташлады да китте. Аңа рәхәт. Аның янында һичьюгы хезмәттәшләре бар. Ә Ләйлә…

Җил исеп куйды, һәм аның күңелен ниндидер салкынлык биләп алды, бөтен булмышын күңелсезлек, сагыну, юксыну тойгысы ялмады, әлеге хисләрнең бер дә юктан гына икәненә үзен ышандырырга теләсә дә, берни дә килеп чыкмады – ул көчсез иде. Берничә көн элек кенә үзенең чиксез мөмкинлекләре белән кызыктырган өй бүген аңа көндәше кебек булып тоелды. Синең иреңне шушы өй ашата, шушы өй йоклата, хәтта никах түшәгендә дә ул килеп кысыла… Соң шулай булгач… Ләйлә ни өчен кирәк Илдарга?! Теләсә нинди хатын белән теләсә нинди ирне яраштырып яшәтә ала ич бу йорт. Моңарчы Ләйлә белән Илдар үз тормышларына үзләре хуҗа, аларның эш-гамәле белән бер-берсенә булган мәхәббәт, ихтирам идарә итә иде. Ә бүгеннән башлап, алар белән шушы йорт идарә итәчәк. Әнә бит, иртән рәхәтләнеп үбешергә дә ирек бирмәде.

– Онытылып китмәгез. Илдар, эшеңә соңлыйсың… – дип, өйгә охшатырга тырышып кабатлады хатын. – Онытылып китмәгез… Илдар, син болай ит… Ә син, Ләйлә, болай эшлә…

Аларны хезмәтләндерергә тиешле булган йорт ник әле хакимлек итәргә тиеш?! Һәркем үз урынын белергә тиеш. Ләйләнең күңелен җылытып торучы бер генә нәрсә бар иде бу мизгелдә. Ул бу йортны теләсә кайсы вакытта сүндереп куя ала. Юк, барыбер ул хуҗа булып чыга. Ул менә хәзер үк бары тик бер кнопкага гына баса, һәм йорт гадидән дә гадигә әйләнә. Хәзер үк сүндереп куярга кирәк. Хәзер үк…

Ләйлә шул уйлар белән өйгә атласа да, ишектән керү белән үзен ниндидер якты нур чолгап алуын тоеп, тыелып торды, ә бер мизгелдән баягы теләге бөтенләй юкка чыкты. Соң шундый соклангыч өйне сүндереп куялар димени?! Бу йорт бит синең җаның-тәнеңне назга, ләззәткә төрә, син үзеңне бәхетле итеп сизсен өчен, бу йорт барысын да эшли. Соклангыч өй бу!

Ул ишек төбендә беркадәр басып торды. Аннан соң кухняга узды. Берәр эш эшләргә кирәкмиме дигәндәй, күзләрен йөгертеп алды. Бөтен җир җыйнак һәм пөхтә иде. Бернигә дә кул тидерерлек түгел. Баягы уй тагын үзен сиздереп куйды. Артыклык тойгысы.

– Ләйлә, син борчылма… – дигән ягымлы тавыш ишетелде. – Әкренләп син барысына да күнегерсең. Теләсәң, без синең белән икәүләп ашарга әзерли алабыз. Илдар кайтуына. Шулай итәбезме?

Хатын, кемнедер күрергә теләгәндәй, алан-йолан каранып куйды. Һәм елмайды:

– Юк… Үзең генә пешерерсең инде…

– Ничек телисең… – Йортның тавышында да елмаю ишетелгәндәй булды. – Әмма беркайчан да үзеңне кирәксез итеп тойма. Мин – сезнеке, һәм мин – сезнең өчен. Әгәр син үзеңне артык дип хис итсәң, мин дә үземнең артыклыгымны тоям. Һәм…

– Һәм икебезгә дә кыен була, – дип дәвам итте аны Ләйлә. – Ярый… Гафу ит… Өйрәнермен әле…

Йорт башкача дәшмәде. Әмма аның сүзләреннән соң Ләйләгә чынлап та рәхәт булып калды. Йорт хаклы иде. Рәхәтлеккә дә күнегергә кирәк. Тарсынып-нитеп торырга, үз кәефеңне үзең җибәрергә ярамый. Һәм ул тагы ваннага атлады. Ял итәргә, гомернең ләззәтле мизгелләрен бөтен тулылыгында татып калырга кирәк. Ләйләнең күз алдында инде су астының соклангыч күренешләре пәйда була башлаган иде…

**6**

– Бер нәрсәдән дә куркасы юк, – дигән иде профессор. – Беләгеңә укол ясыйбыз да берничә минутка менә шушы ваннага кереп ята- сың. Теләсәң, тикшеренүләр барышын күзәтерсең, теләсәң, йоклап ал – ихтыярың. Синнән бары тик бер генә нәрсә таләп ителәә. Баштагы мәлдә фикерләреңне үз кичерешләреңә тупларга тырыш…

Профессорның сүзләренә караганда, бернинди дә авырлыгы булырга тиеш түгел иде. Әмма, укол ясагач ук, Илдар әлеге сүзләрнең хаклыгына шикләнә башлады. Беренчедән, аның тамырына кертелгән сыекча гади укол түгел, зәңгәрсу төстәге куе нәрсә иде. Икенчедән, ул бик тә авырттыра торган нәрсә булып чыкты. Әйтерсең Илдарның тамырлары буйлап кан түгел, ә юлында очраган бөтен нәрсәне дә кырып-себереп ашап баручы монстр хәрәкәт итә иде. Аның бөтен тәне тартышты, күзләре акайды, тешләре шыгырдап кысылды, иреннәре ерылды, битендәге тамырлары бармак юанлыгы булып бүртеп чыкты. Ләкин иң үзәккә үткәне бу түгел иде әле, аның тыны кысылды, бераздан ул үзенең бөтенләй дә сулыш ала алмавын тойды, әйтерсең кемнеңдер күзгә күренмәс кулы бугазыннан каерып тоткан иде. Башта ул бернәрсә дә күрмәде, соңрак күз алдындагы томан тарала төште, һәм үзе тирәли нәрсәдер эшләп йөргән кешеләр шәйләнде. Ләкин бу озакка бармады, бөтенесе дә әкрен генә калейдоскоптагы сурәтләр сыман вак кына кисәкләргә таркалды. Илдарның өстенә иелгән профессорның йөзе, аның артындарак торган Илдус белән Зифа, лабораториядәге күренешләр… Барысы да кечкенә кисәкчәләргә әверелеп, дерелдәп тордылар да җуела башладылар. Әйтерсең болар чынбарлык түгел, ком-

пьютер мониторындагы сурәтләр генә иде. Һәм алар җуелдылар да, күз алдында ап-ак экран гына торып калды… Ап-ак экран гына. Акрынлап, аклык ерагая башлады, һәм бераздан ул, күз күреме җитмәс биеклеккә китеп, зәңгәрсу караңгылык артына яшеренде.

Тирә-якта тик зәңгәрсу караңгылык кына иде.

Илдар күзләрен ачты. Күренеш үзгәрмәде. Бөтен тирә-юньдә – зәңгәрсу караңгылык, ә колакта ниндидер тылсымлы музыка уйный. Ниндидер сихри музыка – тынычландыра, үзенә буйсындырып, бөтен дөньяңны оныттыра.

Һәм ниндидер ис бар сыман… Саф һава… Юк… Тын юлларын иркәли торган саф һәм… бераз гына әчкелтем һава… Һәм салкынлык… ниндидер салкынлык… Ул синең җелекләреңә үтеп кереп калтыранырга мәҗбүр итми, ул бары тик бөтен булмышыңны кытыклатып кына тора.

Бераздан аның баш очында ниндидер шәүләләр пәйда булды. Кешеләр булса кирәк. Әйе, кешеләр… Аларның йөзен дә, гәүдә-кыяфәтен дә аерырлык түгел… Шәүләләр аның янында нәрсәдер эшләделәр. Алар әкрен һәм тавыш-тынсыз иде…

– Укол ясадыңмы? – дип пышылдады кемдер.

– Әйе… – дип җавапладылар. – Хәзер ул безнеке…

– Безнеке… – дип, канәгатьсез пышылдады берәү. – Минем әтине шушы нәрсә үтерде…

Тынлык урнашты.

– Мин беркемне дә үтермәдем… – дип акланды Илдар. Тик аны берәү дә ишетмәде.

Җил исеп куйды. Бу салкын да, саф та җил иде. Ничектер иркәләгән сыман тоелды.

– Юк… – диде кемдер. – Синең әтиеңне бу үтермәде. Бу түгел. Мин үз күзләрем белән күрдем.

– Җитәрегез! – Бу тавыш башлыкларыныкы иде бугай. – Вак-төяк нәрсәләр белән баш катырмагыз. Монда җитди эш бара.

Сөйләшүләр тынып калды.

Шәүләләр нидер эшли иде.

– Син барысын да дөрес эшләдеңме? – дип пышылдадылар бераздан. – Син моның ярдәм итәчәгенә ышанасыңмы?

Әлеге тавышны ул Зифаныкына охшатты. Димәк, ниндидер көтелмәгән хәл килеп чыккан. Көтелмәгән хәл килеп чыккан да, аны кабат дөньяга кайтарырга итәләр. Илдус нидер эшли, ә Зифа аңа ышанып җитми…

– Юк, ышанмыйм… – Монысы… Монысы профессор тавышы булырга тиеш… – Ләкин ни дә булса эшләп карарга кирәк…

– Ярдәм итәргә тиеш…

– Ул селкенеп куйды! – дип, куркып пышылдады берсе… Аны тавышыннан танып булмады… – Безгә китәргә кирәк…

Илдар инде бөтен түземлеген җуйды.

– Китмәгез! – дип кычкырды ул бар көченә. – Нишләп мине мондый хәлдә калдырып китәсез?!

Аны беркем дә ишетмәде.

– Ярдәм итә! – дип пышылдады кемдер. Илдар моны көтмәгән иде, шуңа да тавышны игътибарсыз калдырды. Әлеге мизгелдә аның өчен бары тик бер генә нәрсә мөһим иде – ташлап китмәгәннәр. Хезмәттәшләре аның янында калган! Димәк, ул кире кайтачак!

– Ярдәм итәргә тиеш, әлбәттә. – Бу – профессорның тыныч тавышы иде. – Ә сез нәрсә көттегез?! Колагыгызга киртеп куегыз, кемнедер шушындый сәяхәткә озатасыз икән, сез, эшнең нәтиҗәсеннән бигрәк, тәҗрибә астындагы кешенең исәнлек-саулыгы турында уйларга бурычлысыз.

– Ә мин нык курыккан идем… – диде Зифа. – Чынлап, профессор…

– Берничә минуттан аягында булачак ул. Шуңарчы бөтен нәрсәне әзерләп куегыз.

– Әзер, профессор. – Зифаның тавышында елмаю ишетелде: – Күптән әзер инде.

Илдар да күңеленнән генә елмая иде.

Бераздан ул күзләрен ачты. Илдар бүлмә уртасына куелган пыяла ванна төбендә, ниндидер яшькелт сыекча эчендә ята иде. Аның күзләре ачылганны иң беренче булып Илдус күрде һәм кычкырып җибәрде:

– Ул кайтты, профессор!

Илдар торып утырды. Хезмәттәшләре елмаешып кул чабарга тотынды. Бераздан Зифа белән Илдус аңа аягына басарга булыштылар һәм ванна янындагы келәмгә китерделәр.

– Калганын үзең карый тор, – дип елмайды Зифа һәм, өстәл янына килеп, ирләргә арты белән басты. Шул арада ук махсус җайланма Илдарның юеш киемнәрен салдырды да аның тәнен киптереп, бәрхет халат кидереп куйды. Бераздан, кулына укол тотып, Зифа килеп җитте. Аны күрүгә, Илдар елмаеп куйды:

– Тагын уколмы?

– Монысы куркыныч түгел, – дип елмайды профессор. – Иң авыры үтте инде. Котлыйм сине, Илдар!

– Сезне дә… – диде Илдар, һаман уколдан күзен алмыйча. – Бәлки, берәр таблетка гына бирерсез?

– Илдар! – Зифа бер кулы белән назлы итеп аның муеныннан кочаклап алды, икенчесен ирнең очасына юнәлтте. – Ә син шундый сокландгыч егет…

– Мин егет түгел… – Илдар янбашында чәнчү тоеп тынып калды, чыраен сытты һәм бар гәүдәсе белән Зифага асылынды. – Ү-үте-рә-сең…

Кыска буйлы кыз аның авырлыгын күтәрә алмыйча чайкалып куйды һәм ирне көч белән этеп җибәрде:

– Сытасың бит!.. – дип елмайды ул. – Үзеңә кара да миңа кара…

– Ә нигә? – дип кашларын сикертте Илдар. – Син дә ярыйсы гына!..

– Карагыз әле, профессор. – Илдусның кыяфәте кирәгеннән артык җитди иде. – Перфторуглеродларның тагын бер үзенчәлеген ачыкладык түгелме соң?! Безнең тәҗрибә астындагы кешебез, һушына килү белән, Зифага ташланды. Димәк, перфторуглеродлар потенцияне дә арттырып җибәрә.

– Ахмак! – дип шелтәләде аны Зифа. – Синең уеңда гел бер нәрсә инде…

– Ярый, тынычланыгыз. – Профессор шаярышка чик куйды. – Илдар, син ял бүлмәсенә керәсең. Ә сез… Эшләрегезне төгәлләгез дә – өйләрегезгә. Бүгенгә тәмам.

– Профессор, ә бәлки, минем фатирны юу турында…

– Илдус! – Рамил Әхмәтович бераз сүзсез торды һәм өстәл тартмасыннан ике диск алды: – Син иртәгә шушы мәсьәлә буенча әзер бул. Ә монысы сиңа, Зифа.

**7**

Рамил Әхмәтовичның кыяфәтенә караганда, Илдар белән икесе генә калгач, әллә нәрсәләр турында серләшерләр шикелле иде. Әмма Зифа белән Илдус артыннан ишек ябылуга ук, бүлмәдә тынлык урнашты. Берсе дә башлап эндәшергә ашыкмады. Әле булса ял бүлмәсенә кереп китә алмаган Илдар бөтен тәнендә ниндидер ләззәтле арыганлык тоеп, селкенергә дә иренеп утырса, профессор кашларын җыерып нәрсәдер уйлый, үзе өчен ниндидер бик мөһим нәрсәне хәл итә иде сыман. Илдар аңа карап-карап алды, ләкин бүлдерергә кыймады. Бераздан профессор үзе урыныннан кузгалды. Акрын гына атлап, өстәл янына килде. Ике кулы белән өстәлгә таянып, берничә минут басып торды. Аннан соң Илдарга борылды.

– Мин баягы тәҗрибәне тагын бер тапкыр кабатлау турында уйлаган идем, – диде профессор, хезмәттәшләре артыннан ишек ябылуга. – Бу юлы без икебез бергәләп сәяхәт кылырга тиешбез. Ләкин әле хәлсезләнебрәк торам. Безнең ул сәяхәтне беркадәр вакытка кичектерергә туры килер. Шулай хәтта яхшырак та булыр. Син дә көч туплап, әзерләнеп торырсың. Ә хәзер без синең сәяхәтең турында сөйләшербез…

Рамил Әхмәтович стенадагы электрон сәгатькә карап алды да бөтенләй икенчегә борды:

– Яңа йортта ничек соң? – диде ул, иң мөһим нәрсә турында сорашырга оныткан кеше сыман. – Әле аның бөтен мөмкинлекләрен дә татып карый алмагансыңдыр?

– Юк… – дип елмайды Илдар. – Әмма күргән кадәресе дә башка сыярлык түгел. Әйтеп аңлатып кына бетереп булмый аны. Шундый соклангыч! Рәхмәт инде сезгә, Рамил Әхмәтович!

– Ярый… – Профессор кул гына селтәде. – Ванна кердең инде бүген?..

– Әйе… – Илдар канәгать елмайды. – Аны ванна гына дип әйтергә дә тел бармый…

– Әле эш бүлмәң белән танышып өлгердеңме соң?

Илдар елмайган җиреннән кинәт тынып калды.

– Юктыр әле, – дип, үзе үк җавап бирде профессор. – Эш турында уйлап та карамагансыңдыр. Мин, бер атна яшәгәч кенә, өйдә эш бүлмәсе дә барлыгын белдем.

– Юк… – диде Илдар, җиңел сулап. – Анда аяк та басмадым әле…

– Ярый, өлгерерсең… – Профессор аңа сынап карап торды. – Тик бер киңәшем бар. Эш бүлмәңне сүндереп куй. Вак-төяк нәрсәләрдә, әлбәттә, булыша ул. Әмма фикерне гел читкә, гел кирәксез нәрсәгә юнәлтеп тик тора. Ул йорт – ял итәр өчен, рәхәтләнеп, ләззәтләнеп яшәр өчен. Әмма ул эш өчен бармый. Шуңа күрә иң беренче итеп аны сүндереп куй. Һәм алай итүең турында беркемгә дә әйтмә.

Илдар елмайды:

– Соң аны әйтеп торасы бармыни?! Сүндерү белән билгеле була ич!

– Юк! – Профессор түш кесәсеннән кечкенә диск тартып чыгарды. – Менә кайда аның даруы. Идарә итү пультына кереп, андагы дискны менә шушының белән алыштырып кына куясың. Һәм вәссәлам! Бөтен система төгәл эшли. Ә синең эш бүлмәңнең сүнделүе турында беркем дә белми.

– Ничек инде?! – Илдар шаяртмыймы икән дигәндәй сынап карады. – Алай булмый бит!

– Кил әле монда. – Рамил Әхмәтович аны тәрәзә янына алып килде. – Нәрсә күрәсең?

– Урам…

– Хәзер менә бу кинокамера аша кара. – Профессор, өстәл тартмасыннан кечкенә кинокамера алып, Илдарга тоттырды. – Кинога төшер урамны.

Илдар бертын урам күренешен төшерде дә профессорга борылды:

– Шуннан нәрсә?

– Менә болай. Синең кулыңда – урамны күзәтергә куелган камера. Ул урамда ниләр булганын төшерә. Ә сакчы – әйтик, урамдагы тәртип өчен җавап бирүче кеше – шушы камерадан күзәтә. Әгәр урамда ниндидер гадәттән тыш күренеш бар икән, ул шундук тиешле җиргә хәбәр итә. Хәзер без шушы камерадагы дискны алыштырып куябыз…

Рамил Әхмәтович чынлап та дискны алыштырды.

– Менә кара, – дип, ул камераны кабат Илдарга бирде. – Нәрсә күрәсең?

– Урам күренеше…

– Аңладыңмы инде?! – Профессор, ниһаять, төшендерә алуына сөенгән кебек иде. – Синең камерада да – урам күренеше. Гадәти урам күренеше. Һәм син, шушы күренешкә карап, урамда барысы да тәртиптә дип уйлыйсың…

– Ә асылда мин чынбарлыктагы урамны түгел, ә алдан төшерелгән нәрсәләрне күрәм… Шулаймы?!

– Синең эш бүлмәң белән дә шундый ук принцип килеп чыга. Аз гына катлаулырак процесс. Әмма нигезендә шушы күренеш ята. Һәм беләсеңме нәрсә?

– Нәрсә?

– Мин ул дискны сиңа бүләк итәм.

Илдар елмайды:

– Рәхмәт, Рамил Әхмәтович…

– Ярый. Әмма бүлмәнең сүндерелүе хакында беркемгә дә, хәтта хатыныңа да әйтмә. Килештекме?!

– Килештек.

– Мә.

Икесе дә көлешеп алдылар.

– Моннан ары сиңа өйдә дә эшләргә туры киләчәк, – диде профессор, үзенең юмартлыгы өчен акланырга теләгәндәй. – Күбесенчә өйдә эшләргә туры киләчәк. Һәм мин синең юкка-барга бүленүеңне теләмим.

– Аңлашыла…

– Һәм тагы бер нәрсә. – Профессорның кулында кечкенә флакон пәйда булды. – Менә бу сыекчаны син бүген үк, өеңә алып кайтып, иң ышанычлы урыныңа яшереп куясың. Мин аның нәрсә икәнен дә, ни өчен кирәклеген дә әйтмим. Вакыты җиткәч, син аны кайда, кайчан һәм ничек кулланырга кирәген үзең аңлаячаксың. Килештекме?!

– Килештек.

– Мә.

Профессор тагын көлеп җибәрде. Аңа Илдар да кушылды.

– Ә хәзер, – профессор тагын җитдиләнде, – без синең сәяхәтең турында сөйләшергә тиешбез. Әлеге тәҗрибәне син ничек күрдең,ниләр кичердең, гомумән, бу вакыйга турында нәрсәләр хәтерлисең – барысын да төкми-чәчми сөйләп бирергә тиешсең.

– Килештек… – дип елмайды Илдар.

– Ярый, син әзерләнә тор, ә мин менә монда бераз тәртип урнаштырам.

Профессор өстәл артына барып утырды. Илдар үзенең күргәннәрен бөртекләп сөйләргә җыенды һәм елмаеп куйды. Сөйләрлек бернәрсә дә юк иде. Профессор озак утырмады.

– Башладыкмы? – диде ул өстәлдән тору белән. – Син әзерме?

– Әзерен-әзер… – Илдар гаепле елмаеп куйды. – Ләкин мин берни дә сөйли алмыйм. Зифа беләгемә укол ясады һәм… Һәм мин ванна эчендәге су төбендә уянып киттем… Бары тик шул гына…

Профессор аңа бертын сынап карап торды да елмаеп җибәрде:

– Ярый. Шунысы да бик җиткән. Син бүген арыгансыңдыр инде. Кайтырга да мөмкиндер.

**8**

Илдар чыгып киткәч, Рамил Әхмәтович үзалдына елмаеп куйды. Ул аннан да, үзеннән дә канәгать иде. Бүгенге тәҗрибәләр уңышлы үтте. Әлбәттә, бу әле – алда торган зур эшнең башы гына, әмма Илдар – нык характерлы егет, һәм профессорның аңа ышанычы чиксез иде.

Рамил Әхмәтович лаборатория белән идарә итү бүлмәсенә керде. Бу кечкенә, метр ярымга метр ярымлык кына бүлмә иде. Ишектән узу белән, каршыда идарә итү өстәле тора, өстәлнең буеннан-буена стенага беркетеп эшләнгән яссы мониторлар тезелеп киткән, аларда бүлекнең дүрт бүлмәсе дә күренә иде. Профессор, өстәл янына килеп, төймәләргә баскалады. Экраннарда бернинди дә үзгәреш булмады, бары тик өстәл астындагы процессорның диск куйгычы гына ачылып китте…

Бу – Илдарга биреп җибәргән диск шикелле нәрсә иде, лабораториянең автоматлаштырылган хезмәтләндерү системасын өлешчә сүндереп тора. Рамил Әхмәтович аны эшендә дә, өйдә дә гел сүндереп куя иде. Әлеге системаны санга сукмаган өчен түгел. Юк. Бары тик ул әлеге тормышны башка галимнәрдән яхшырак аңлый, һәм әлеге система уңайлыклар тудыру белән бергә һәрбер кешене күзәтү, уч төбендә тоту өчен эшләнгәнен дә белә иде. Урамнарда да, аулаграк урыннарда да – беркайда да тәртип сакчылары йөрми. Әмма җинаятьчелек бөтенләй юк диярлек. Кешенең аң һәм акыл дәрәҗәсе югарырак булган өчен түгел, әлбәттә. Бары тик көнкүрешнең бөтен өлкәсенә дә үтеп кергән автоматик хезмәтләндерү, ә асылда, автоматик күзәтү системасы, ә тагы да төгәлрәк итеп әйткәндә, автоматик идарә итү системасы булганга. Синең һәрбер адымыңны, уйларыңны, импульсларыңны күзәтү астында тота торган система…

Профессорның Илдарны юк-бар сүзләр белән игътибарны алып, тоткарлап торуы да аның лабораториядә нәрсәләр белән шөгыльләнүен оныттыру өчен иде. Ваннадан чыгу белән кадаган укол үз эшен эшләп өлгергәнче, Илдар беркая да чыгарга тиеш түгел иде. Юкса аларның монда нәрсә белән шөгыльләнүе шул мизгелдә үк билгеле булачак. Ә бу – һәлакәт дигән сүз.

Аның кул астындагылар үзләренең перфторуглеродлар тудырган мөмкинлекне файдалану юлларын эзләү белән шөгыльләнүенә чынлап та ышана иде. Бу гаҗәп түгел. Алар яшәгән дөньяда һәр ун кешенең берсе галим, һәм алар нинди дә булса ачыш ясау белән мәшгуль. Чынлап та, зур ачышлар ясыйлар, һәм бу ачышларның берничә гасыр элек үк билгеле булганлыгы турында бөтенләй белмиләр иде.

Бу дөньяда тормышның асылын аңлаучылар бармак белән генә санарлык, һәм аларның язмышы – кыл өстендә. Профессор Гаскәров шундыйларның берсе иде. Әмма ул үзе ачкан чынбарлыкны үзе күтәрә алмыйча һәлак булды. Бу да гаҗәп түгел. Тормышка күзләре ачылгач, акылдан шашучылар да, йөрәге ярылып үлүчеләр дә аз булмас әле. Шуңа да нык характерлы, салкын акыллы кешеләр кирәк. Әмма андыйларны табу ай-һай авыр. Рамил Әхмәтовичның бөтен ышанычы Илдар иде…

Рамил Әхмәтович тәҗрибәләр үткәрү бүлмәсенә чыкты. Идарә пультының төймәләренә баскалады. Бераздан бүлмә уртасында баягы пыяла ванна пәйда булды. Шул арада ук эшкә керешкән алтынсыман төстәге беләк юанлыгы сыек торбалар аны зәңгәрсу сыекча белән тутыра башлады. Рамил Әхмәтович приборлар шкафына килеп аннан шприц алды, кирәкле флаконнан сыекча суыртты. Шприцлар икәү иде. Ул аларның икесен дә тутырды да, азак берсен зуррак флаконга бушатты. Тулы шприцны беләгенә кадады. Авыртудан бөтен мускуллары киерелде. Әмма профессор бирешмәде. Үзе кулланган шприц белән флаконны ул кабат ниндидер сыекчалар белән тутырды да шкаф шүрлегенең түбәнәрәк тыкты. Ә бая ук бушатып куйганнарын ванна янындагы тумбочкага алып килде. Аңа һәрбер хәрәкәт зур авырлык белән бирелә иде. Аякларын көчкә күтәреп ванна янындагы келәмгә басты, һәм шундук диярлек өстендәге киемнәре юкка чыкты да, махсус трусиктан гына калды. Профессорның тамырлары бүртеп, бөтен тәне яшькелт зәңгәр төскә кергән иде. Ул, бар ихтыярын туплап, ваннага килде. Аякларын күтәрерлек хәле юк иде. Ул бертын уйланып торгандай итте. Һәм ваннага арты белән борылды, ике кулы белән аның ике як читенә таянып, акрын гына эчкә шуып төште.

– Карале, ничек шулай булдыра ала ул! – Экранга төбәлеп утыручы ирләрнең берсе телен шартлатып куйды. – Бер тамчы су да чәчрәмәде…

Әмма иптәше аның соклануларын бүлешмәде. Ул кечкенә буйлы ябык гәүдәле адәм иде. Башының алгы ягы пеләшләнеп, лепкәсенә кадәр менгәнлектән, аны мондагы акыл ияләренең берсе дип уйларга мөмкин. Ләкин ул – бернинди дә галим түгел, ә бары тик Фәннәр академиясенең эчке тәртип буенча гади хезмәткәре генә. Хәер, аның вазифасы галимнәргә караганда югарырак бәяләнә, һәрхәлдә, тәртип сакчыларын катлаулы тестлар ярдәмендә сынап, иң ышанычлы кешеләрдән генә билгелиләр иде.

– Карале, Гомәр… – дип, тагын нәрсәдер әйтмәкче булды теге.

– Әйдә! – Гомәр инде чыгарга әзер иде. – Без тиз арада әйләнеп килергә тиешбез.

– Җитешәбез әле… – дип, юан гәүдәсен урындыктан кубарды Хәниф. – Шулкадәр һушсызланып кереп киткәч, ул ярты сәгатьсез адәм булмый әле…

Алар профессорның лаборатория белән идарә итү бүлмәсенә охшаш, әмма берничә тапкырга зуррак кабинетта утыралар иде. Ишек төбендәге келәмгә барып басу белән, икесенең дә өстендә көмеш төсендәге махсус костюмнар пәйда булды. Һәм алар, артык сүзгә вакыт әрәм итми генә, коридорга атладылар.

Профессорның лабораториясенә кергәч, Гомәр чыраен сытып куйды.

– Карале, ниндидер әчкелтем ис… – диде Хәниф, – шушында ничек түзеп утыралар микән?..

Гомәр бүлмәгә күз йөгертте.

– Кайдан башлыйбыз? – Хәниф өстәл янындагы шкаф алдына килеп басты: – Монда-а-а..

– Нәрсә? – Гомәр аны кырыс кына бүлдерде. – Анда нәрсә?

– Монда бары тик дисклар гына, – диде Хәниф, шкаф ишеген ябып. – Ә без эзләгән пакет күпкә калынрак һәм…

– Тавышланма! – Гомәр һаман кырыс иде. – Тавышланмый гына эзлә. Шкафлар, өстәл тартмалары, гомумән, кайдан мөмкин – шуннан…

Хәниф башкача бер сүз дә дәшмәде. Ул эшкә кереште.

Озак маташтылар. Бер бүлмә дә, аның бер генә урыны да игътибардан читтә калмады. Хәтта чүп савытлары да актарылды. Әмма бернәрсә дә табылмады.

– Юк, – диде, ниһаять, Хәниф, авыр сулап, – берни дә юк…

Бераздан ваннада яткан профессор селкенеп куйган кебек булды. Моны иң беренче булып Хәниф күрде.

– Профессор уяна, – диде ул, пышылдауга күчеп, – ул кузгалып куйды.

Гомәр баш какты да ишеккә ымлады. Хәниф шунда атлады. Карашлары белән бөтен бүлмәне тагы бер кат тикшереп чыккач, Гомәрнең күзе ванна янындагы тумбочкада яткан шприцка төште. Ул бертын уйланып торды да аны, целлофан пакетка төреп, сумкасына тыкты. Ә аның урынына шундый ук буш шприц калдырды. Бу хакта ул монитордан профессорның эшен күзәтеп утырганда ук уйлаган иде. Һәм, бүлмәгә тагын бер кат күз йөгертеп, ишеккә атлады.

– Без нәрсә эзләдек соң? – диде Хәниф, үз бүлмәләренә кайткач.

Гомәр аңа бертын сынап карап торды да мыскыллы елмаеп куйды:

– Пакет, – диде ул, иптәшенең тилелегенә үртәлеп. – Егермегә ундүрт сантиметрлы ак төстәге пакет. Калынлыгы ике сантиметр чамасы. Без менә нәрсә эзлибез.

Хәзер инде Хәниф елмайды.

– Анысын беләм, – диде ул, иптәшенең сантыйлыгына һич аптыраусыз. – Ләкин ул пакет эчендә нәрсә соң?

– Ә моны белү сиңа мәҗбүри түгел, – диде Гомәр коры гына, – монысы сер.

– Димәк, син үзең дә белмисең, – дип елмайды Хәниф. – Аңлашыла…

– Эш бөтенләй дә анда түгел. – Гомәр нәрсәгәдер үртәлә иде. – Ул пакетның шушы лабораториядә икәнлеге шиксез. Һәм безгә аны табарга кушылды. Һәм без табарга тиешбез.

– Димәк, без эзләгән нәрсә бу лабораториядә түгел, – диде Хәниф. Гомәрнең үз эшен нык бирелеп эшләгәнен ул белә һәм уңышсызлыклар вакытында аның йөрәгенә шулай шом салып, җанына тиеп алырга ярата иде. Бу юлы да иптәшенең кабарынып китүен көткән иде. Әмма Гомәр тыныч калды.

– Ә кайда соң? – диде ул, Хәнифтән киңәш көткәндәй. – Кайда?

**9**

Хатыны Илдарны болдырга ук чыгып каршылады.

– Беләсеңме, кадерлем… – диде ул сүзләрен әйтеп өлгерә алмаудан курыккандай, – синең якынлашуың турында миңа йорт хәбәр итте. Мин бизәнү бүлмәсендә идем… Ул миңа синең кайтуыңны әйтте. Ә киенеп залга чыксам, кухняда аш пешә башлады, синең кием шкафың хәрәкәткә килде… Өй түгел бу, ә ниндидер могҗиза!

Илдар аны кочаклап алды.

– Ә мин сине шундый сагындым… – диде ул, хатынының иреננә сарылып. – Сагындым…

– Мин дә… – Ләйлә аны акрын гына ишеккә юнәлтте. – Мин сине…

Йортка узып, артында ишек ябылу белән, Илдар аны күтәреп алды да йокы бүлмәсенә юнәлде. Эштән киткәндә, ул үзендә чиксез арыганлык тойган сыман иде. Әле бернинди дә уңайсызлык сизелмәде. Ул көчле, дәртле, гайрәтле иде.

– Бердәнберем минем… – дип, кайнар пышылдады хатын, аның уң кулы иренең муеныннан кысып кочаклаган, ә сулы аның күлмәк төймәләрен ычкындыра иде. – Сагындым сине шундый…

…Ашап алгач, Ләйлә Илдарны бергәләп ванна керергә кыстады. Әлбәттә, ирнең теләге зур иде. Әмма ул үзенең эш бүлмәсен кереп тә күрмәвен уйлап баш тартты:

– Соңрак, кадерлем… – дип елмайды ул. – Минем әле бераз эшем бар.

– Юкка баш тартасың, – дип, иреннәрен очлайтты хатын, – ярый, үз иркеңдә. Әгәр эшләреңне тиз генә бетереп, бергәләшеп коенып чыгарга уйласаң, мин ваннада булам…

– Ә мин уйлармын… – диде Илдар. – Һәм коенып чыгарга гына да түгел…

– Ярый… Көтәм…

Эш бүлмәсе лабораториядәге алгы бүлмәдән артык аерылмый иде. Тупсадан узу белән, ягымлы тавыш яңгырады.

– Сез үзегезнең эш бүлмәгезгә кердегез. Автоматик хезмәтләндерү системасын кушып, кирәкле нәрсәләр белән танышуыгыз сорала…

Илдар, тавышка бөтенләй игътибар итмәстән, тирә-якка күз йөгертте. Бүлмә түрендә – ишеккә карап торган кызгылт төстәге зур гына пластик өстәл. Аның өстендә – берничә яссы монитор һәм компьютер клавишлары, өстәл артында – зур кәнәфи. Кәнәфинең аркасында – әллә нинди корылмалар. Илдар әлегә андагы колакчын белән баш миендәге импульсларны билгели торган шлемны гына таный алды.

Сул як стенаның буеннан-буена шкафлар тезелеп киткән. Беренче карашка аларның шкаф икәнен дә аерырлык түгел, бары тик тартмалар һәм ишекләрдәге ачкыч-клавишлар гына сатып тора. Ә уң як стенага тулысы белән сыек экран көйләнгән икән. Илдар моны өстәл артына утырып, пультларга баскалап карагач кына төшенде. Бер мизгелгә стенада су өстенә таш ташлагандагы шикелле дулкыннар пәйда булды да, бераздан ул урамга әйләнде. Теләсәң, чыгып йөреп керергә дә мөмкин. Яңа урыннарда гел шулай урам күренеше куелган була. Аннан соң хуҗа аны үзе теләгәнчә үзгәртә. Илдар стенадагы сыек экранны сүндерде дә шкаф янына килде.

– Сез үзегезнең эш бүлмәгезгә кердегез. Автоматик хезмәтләндерү системасын кушып, кирәкле нәрсәләр белән танышуыгыз сорала… – диде теге тавыш.

Илдар елмаеп куйды да шкафларның ишекләрен ачкалап карады. Әле бернәрсә дә юк иде. Ялтырап торган пластик шүрлекләр. Дисклар, колбалар, тагын әллә нәрсәләр куяр өчен җайланмалар. Озакламый болар шыплап тулачак инде. Илдар тагын берничә ишекне ачып карады да өстәлгә терәлеп диярлек торган шкафка килде. Бүтәннәр белән бер үк төстә булса да, монысы аерыла иде. Илдар, үз уйларын куәтләргә теләгәндәй, бармак сырты белән ишеккә сугып карады. Тавыш чыкмады да диярлек. Бу ниндидер ныклы материалдан иде.

– Сез үзегезнең эш бүлмәгезгә кердегез. Автоматик хезмәтләндерү системасын кушып, кирәкле нәрсәләр белән танышуыгыз сорала…

– Ярый, – диде Илдар, үртәлә башлап. – Кушармын барысын да. Тын гына тор әле.

– Сез система таләпләрен бозасыз, – дип, үзенекен тукыды баягы тавыш, – әгәр инструкцияләрне төгәл үтәмисез икән, бу көтелмәгән нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Автоматик хезмәтләндерү системасын кушып, кирәкле нәрсәләр белән танышуыгыз сорала…

Илдар авыр көрсенде дә тагын өстәл артына барып утырды. Кирәкле төймәләргә баскалады. Ниндидер тылсымлы музыка уйный башлады.

– Автоматик хезмәтләндерү системасы уңышлы кушылды, – дигән тавыш ишетелде бераздан. – Тиешле инструктаж үтү өчен, колакчынны киегез дә креслога җайлап утырыгыз.

Илдар кушылганны эшләде. Креслога киерелеп утырып тынып калды. Аның йөзе җитди иде. Ара-тирә сизелер-сизелмәс кенә баш кагып та алгалады. Бераздан колакчынын салып, урынына куйды. Тагы музыка ишетелде.

– Бераз ял итегез, – диде ягымлы тавыш. – Система сезнең таләпләргә яраклашу процессын башлый. Аз гына көтәргә туры киләчәк.

Ягымлы, якты музыка астында вакыт бик тиз үткәндәй тоелды. Илдар татлы изрәп утырган җиреннән янә таныш тавышны ишетте:

– Автоматик хезмәтләндерү системасы куллануга тулысынча әзер. Барлык таләпләрне дә җиренә җиткереп башкарганыгыз өчен рәхмәт.

Тагын кыска вакытлы музыка яңгырады һәм:

– Илдар, мин тулысынча синең карамакта, – дигән ягымлы тавыш ишетелде. – Синең зур көч таләп иткән эшеңдә ярдәмчең булырмын дип ышанам.

Илдар елмаеп куйды. Шушындый күзгә күренмәс хезмәтчең булу кызык та, рәхәт тә иде. Ул тагын беркадәр тын гына утырды да бүлмәдән чыгып китте. Озакламый, Рамил Әхмәтович биргән нәрсәләрне алып, кабат килде һәм системадагы дискны алыштырды. Һәм тагын елмайды. Бая гына бүлмәдә кемдер бар шикелле иде. Күзгә күренми торган ниндидер көч барлыгы үзен сиздерә, һәм бөтен фикер көчең шул затны күрәсе килүгә сарыф ителә иде. Әле бу тойгы юкка чыкты. Ул үзенең эш бүлмәсендә берьялгызы калгандай булды. Ул беркемнең дә күзәтүе астында түгел иде. Аннан соң баягы ныклы шкаф янына килеп, ишекләрен ачып җибәрде. Шкаф ныклы материалдан булгач, аның эчендә ниндидер бик затлы әйбер булыр шикелле тоелган иде. Әмма ул буш булып чыкты. Башкалары шикелле үк буп-буш. Илдар бермәл аптырабрак торды да Рамил Әхмәтович биргән флаконны шүрлекләрнең берсенә куйды. Аннан соң шкафның ишеген япты да чыгарга җыенды. Ләйлә инде көтә-көтә көтек булгандыр. Бергәләп су коенырга, йөзеп уйнарга… Ишек тоткасына үрелүгә, бүлмә телгә килде. Илдар аны бөтенләй сүндердем дип уйлаган иде, көтелмәгән тавыштан аптырап китте һәм кире борылды.

– Илдар, – диде ягымлы тавыш, – син шкафны дөрес япмадың…

Илдар, дөрес итеп яңадан ябарга теләп, шкаф янына килде һәм шүрлеккә карап катып калды. Бая гына ул калдырган флакон янында ниндидер ак пакет ята иде. Илдар, үз күзләренә үзе ышанырга теләмичә, аны кулына алды. Бер карышка ике карыш чамасы зурлыктагы бу пакет авыр гына иде. «Ярты кило бардыр», – дип уйлады Илдар. Һәм бу уй аны сискәндереп җибәрде. Шундый зур һәм авыр нәрсәне ул ничек күрми калган? Мондый хәлнең булуы мөмкин түгел иде. Димәк, әлеге пакет шкаф эчендә яңарак кына барлыкка килгән, яки моңарчы ул күзгә күренмәс хәлдә булган. Боларның икесе дә сәер иде. Илдар конверт рәвешендәге пакетны ачты да эчендәге нәрсәне күреп катып калды. Бу бик борынгы нәрсә булырга тиеш иде. Илдар аның нәрсә икәнен дә чамалый шикелле иде. Ул аны конверт эченнән алды да бармаклары белән угалап карады. Кәгазь. Әлбәттә, борынгы әйбер. Хәзерге заманда кәгазьне каян табарга мөмкин, ди…

Илдарның кәгазь турында ишеткәне дә юк иде. Моннан берничә атна элек кенә, алдагы тәҗрибәләргә әзерлек вакытында, Рамил Әхмәтович сөйләде. Борынгы заман кешеләре кәгазьне чамасыз күп кулланган, хәтта туалет хаҗәтләренә дә кәгазь файдаланганнар, һәм шул кәгазь акча буларак та хезмәт иткән. Илдар туйганчы көлгән иде ул вакытта… Ләкин профессор аның шаярырга маташуын җавапсыз калдырды. Мәгълүмат йөртү чарасы да кәгазьдән булганлыгын әйтте ул. Кәгазь битләренә төрле тамгалар төшереп эшләнгән шул мәгълүмат йөртү җайланмаларын төрле исемнәр белән атаганнар. Газета, журнал, китап… Болары иң нык таралган нәрсәләр булган. Һәм әлеге нәрсәләрне беркемгә дә сөйләмәскә, онытырга кушкан иде профессор. «Бу белем сиңа әлегә кирәкми, һәм син аны онытырга тиешсең, – дигән иде ул. – Вакыты җиткәч, син аны искә төшерерсең һәм кайда, кайчан, ничек кулланырга икәнен үзең аңларсың…» Моңарчы чынлып та оныткан иде Илдар. Әле исенә төште…

Ул кулындагы табышка тагын беркадәр карап торды. Борынгы агачны эшкәртеп ясалган табигый кәгазь битләрдән торган бу китап кәгазь катыргы белән тышланган, ялтыр тышлыгына зур, алтынсыман хәрефләр белән авторның һәм әсәрнең исеме язылган. Һәм ул «КИТАП»

дип атала иде. Әйтерсең нәшер итүчеләр бу язманың берничә гасырдан соң табылачагын, ә ул чорда инде «китап» дигән төшенчәнең бөтенләй юкка чыгачагын алдан белеп эш йөрткәннәр. Киләчәк буын кешеләре: «Бу нәрсә икән соң?» – дип аптырап тормасын өчен, аның тышына зур хәрефләр белән «КИТАП» дип язып куйганнар.

Бәлки, чынлап та шулай булгандыр. Әмма наширләр, ничек кенә алдан күрүчеләр булмасын, бер нәрсәне исләреннән чыгарган – дәверләр үзгәрү белән кешеләр дә, шул исәптән телләр дә үзгәрә, бер төрле төшенчәләр, анахронизмга әйләнеп, кулланыштан төшеп кала, алар урынына яңа сүзләр килә. Әлеге табылдыкның тышына зур хәрефләр белән КИТАП дип язып куелса да, бу сүз бүгенге заманның гади кешесе өчен берни дә аңлатмый иде.

Ләкин Илдар гади кеше түгел иде. Рамил Әхмәтович аңа мәҗбүри рәвештә диярлек борынгы символларны өйрәткән иде. Ул вакытта әлеге эш Илдарга мәгънәсезгә вакыт үткәрү сыман тоелды. Хәтта профессор миннән нәрсәгәдер көлә шикелле, ни өчендер мыскыл итәргә тели, дигән уй да килгәләде башына. Әмма бу фикере шундук юкка чыкты. Ул Рамил Әхмәтовичның яхшы кеше икәнен белә һәм аңа тулысынча ышана иде. Өйрәнергә куша икән, димәк, шулай кирәк. Ләкин нигә иркенләбрәк эшләү мөмкинлеге бирмәскә? Шулкадәр нәрсәне берничә сәгать эчендә ерып чыгып буламыни?! Ләкин, кич җитүгә, бу уе да таралды. Профессор һәрвакыттагыча хаклы булып чыкты. Илдар ул биргән тамгаларны таный гына түгел, ә тамганы тамгага кушып укый да ала иде инде. Һәм искиткеч кызык нәрсә икән – әлеге тамгалар белән кешенең сүзләрен билгеләп була… Илдарга бу кызык та, сокланггыч та булып тоелган иде. Хәтта үзенең фәнни эшчәнлеген шушы темага багышлау турында да уйлаган иде. Һәм… Һәм, лабораториядән чыгуга, барысы турында да онытты. Әле менә, кулына китап килеп эләккәч, ул һәммәсен искә төшерде һәм канәгать елмаеп куйды. Әлбәттә, ул үзенең белемен генә түгел, ә Рамил Әхмәтовичның кисәтүләрен дә исенә төшерде. Бу белемнәрне беркем белән дә уртаклашырга ярамый. «Син боларның берсен дә белмисең. Кирәкле чагыңда гына хәтерлисең дә, кирәге беткәч онытасың, – дип кабатлады ул үзенә. – Аш сиңа ачыкканда гына кирәк, йокы – арыганда гына. Әлеге белем дә шулай ук. Ул сиңа бары тик ниндидер мәсьәләне чишкәндә генә кирәк…» Ләкин ул үзен бу уйларына ышандыра алмады.

«Аң астыңа беркетеп куй, – дигән иде профессор, – үзеңнең гыйлемле икәнеңне аңлаган көннән алып, син – куркыныч кеше.»

Кинәт Илдар буыннарының йомшарып китүен тойды. Ул, сыңар кулы белән өстәлгә таянып, акрын гына креслога килеп утырды. Мондый очракта бүлмә аны юатырга тырышыр, нинди дә булса музыка куяр, рухын дәваларлык импульслар җибәрер иде. Әмма аңа беркем дә ярдәм итмәде. Автоматик хезмәтләндерү системасын ул сүндергән иде. Хатыны – ваннада. Йөрәгең ярылып үлсәң дә, йөгереп килүче булмас. Ул креслога утырды да өстәлгә башын салып тынып калды. Күзгә бәрелеп торган сәбәп булмаса да, ул үзе өчен барысы да үзгәргәнен яхшы аңлый иде. Гадәтләнгән тормыш инде артта калды. Ул хәзер – шушы сокланггыч дөньяның гади бер галиме түгел, ул куркыныч кеше иде.

Илдар кулындагы табылдыкка тагын беркадәр карап торды да беренче битен ачты. Тамгаларга күз йөгертте.

Хәзер эш бүлмәсеннән тиз генә чыга алмаячагын чамалый иде инде. Бу китап монда бер дә юктан гына пәйда булмаган, һәм Илдар аны укырга, нәкъ менә хәзер, нәкъ шушы вакытта укырга тиеш иде.

## 10

## «КИТАП» тан өзекләр

* * *

Миңа калса, бөтенесе дә гади генә бер бәхәстән башланды.

Даутовны сез беләсез микән?.. Абрар Муса улын… Ә минем бүгенгедәй күз алдымда әле.

Телевизор экраннарыннан да, газета-журнал битләреннән дә бик сөйкемле булып күренә. Озын буйлы, зифа гәүдәле. Бөдрәләнебрәк торган коңгырт чәчләре тагын да ныграк сөй-

кемлелек өстәп җибәрә. Ә елмайганда ялтырап киткән тигез тешләре күзнең явын алырлык дәрәҗәдә булып, аның елмаюын тагы да яктырак итә. Әлбәттә, әгәр ул акыллы фикерләре белән күңелләрне яуламаса, боларның берсе дә, хәтта Айдар Галимовныкына1 охшабрак торган бәрхет тавышы да шаккатыра алмас иде. Ул һәрбер сүзен нәкъ үз вакытында, нәкъ үз урынында әйтә. Һәм һәрвакыт син көткән, син ишетергә теләгән фикерне җиткерә. Телевизор караганда да, газета укыганда да аны теләктәшең, фикердәшең итеп күрәсең һәм хәтта үз мәнфәгатьләреңә каршы килә торган уйлары белән дә бер каршылыксыз килешәсең. Бер сүз белән әйткәндә, күз сирпү белән хатын-кызның акылын җуйдырырлык, ә ир-атларда хөрмәт уятырлык шәхес. Моңа тагын аның бик югары урында утыруын, бик бай әфәнде булуын һәм өйләнмәгәнлеген дә өстәсәң…

Ул чакта Даутов бик билгеле кеше түгел иде әле. Әлбәттә, үз даирәсендә, сәясмәннәр һәм бай түрәләр арасында аның абруе элек тә зур иде, ә ил буенча… Һәрхәлдә, ул вакытта мин аның кем икәнен дә белми идем.

Мин ул вакытта бары тик язучылык белән генә шөгыльләнә идем. Бүген безнең һөнәр кешеләрен хәтерләүче юк диярлек инде. «Әдәбият» дигән төшенчә кулланылыштан төшеп калды. Ул чорда да бу эш лотерея уены сыманрак нәрсә иде – йә уңышка ирешәсең, яки ирешмисең. Өлешеңә шушы ике юлның кайсы төшсә дә, үзеңне бәхетле дип саный алмыйсың, чөнки китапларың алып килгән дәрәҗә сине мул, иркен тормышка чыгармый. Бу – аз санлы халыкның әдипләре өлешенә төшкән котылгысыз язмыш. Һәм иҗатчыларның барысы да моны аңлап, чамалап тора. Дөресен әйткәндә, алар белән матди табыш артыннан куу теләге идарә итми, алар язган әсәрләре белән халыкның яшәешен бизәргә, күңелен матурларга омтылалар һәм үзләрен рух сакчысы итеп күрәләр. Бу кыланышлары өчен аларны берәүләр изгегә, берәүләр сантыйга исәпли. Мин дә менә шул кавемнең бер кисәге идем.

Язылган әсәрләр бик күп, тик аларның берсе дә китап булып чыкмый, һәм мин очраклы акчага көн күреп яшәргә мәҗбүр идем. Берәр повесть журналларда дөнья күрсә, бу бик зур вакыйгага әйләнә. Юк, укучылар өчен түгел, ә минем өчен. Укучылар арасында да йә телефоннан шылтыратып, йә үземне очратып мактап яки сүгеп китүчеләр табыла, ләкин күпчелек аларны укымый, укыса да ошатмый, ошатса да, эндәшми калуны хуп күрә. Ә минем өчен укучылар фикере артык мөһим дә түгел кебек, әсәрнең басылып чыгуы үзе үк сөенеч – чөнки ярыйсы гына гонорар түлиләр, һәрхәлдә, минем ярлы язмышымда ул бик зур булып күренә иде.

Мин китап кибетләренә кермәскә тырышам, андагы киштәләрдә тезелеп торган чит ил язучыларының унар-егермешәр том китапларын күргән саен, җаным әрни, мин дә алардан ким түгел бит, мин дә, шулкадәр китаплар чыгарып, данлыклы һәм бәйсез язучы булып яши алыр идем, дип уйлыйм. Бу уй минем бөтен кәефемне кыра, үземнең мескенлегемне искә төшерә. Кайчагында хәтта үз талантларын бар дип белмәгән халкыма да, аны шушы хәлгә төшергән ата-бабаларга да рәнҗеп куям. Күп санлы, дәүләтле милләт булсак, безнең китапларны укучылар да күп булыр иде. Китап кадерен белгән кешеләребез күп булса, халыкның үз-үзенә булган ихтирамы артыр, ул үз тормышына аек күз белән карар дәрәҗәдә булыр иде. Һәм бәйсез, иркен тормышлы иҗатчылар тагы да яхшырак әсәрләр язар иде. Бу «иде» ләрне санап кына бетерерлек түгел. Һәм алар миңа беркайчан да тормышка ашмаячак хыял гына булып тоела.

Берничә ай элек кенә «Китап» нәшриятының директорына кереп чыккан идем. Калын гына берәр китап чыгарып булмасмы дип инде. Ул болай диде: «Без һәр авторның җыентыгын биш елга бер генә чыгарабыз. Синең китабың былтыр гына дөнья күрде, шулай булгач, тагы дүрт ел көтәргә туры килер».

Язучы биш елга бер китап кына язып тора алмый, һәм биш елга бер генә китап язган кешене «язучы» дип атау да дөрес түгелдер. Димәк, бездә язучылыкны юк итү күренеше дәүләт нәшриятлары дәрәҗәсендә рәсмиләштерелгән булып чыга. Мин директорга мондый нәрсәнең әдәбиятны – димәк, мәдәниятнең умыртка сөяген – бетерүгә юнәлтелгән гамәл ика-

нен аңлатырга тырышып карадым. Әмма ул берни дә ишетергә теләмәде. Һәм мин өметсезлеккә бирелеп чыгып киттем. Күңелдә әрнү иде. Юк, үзем китап чыгара алмаган өчен түгел… Ә нәшрият директоры булып утырган кешеләрнең шундый мөнәсәбәте, үз халкына булган битарафлыгы өчен. Әгәр эшләр шулай барса, бер ун-унбиш елдан безнең телдә китап укырлык адәм калмаячак, ә бер йөз-йөз илле ел узуга, Җирдә яшәүче милләтләр исемлегеннән бөтенләй югалачакбыз. Шуны беркем дә аңламый микәнни соң?! Аңлыйлар инде, әлбәттә. Ләкин беркем дә моның өчен борчылмый. Көндәлек мәшәкатьләр, корсак хәстәре янында ул чынбарлык булып тоелмый, тоелса да, бик тә ерак, безнең гомердә генә килеп җитмәстер кебек тоела. Бу, күрәсең, югалуга дучар ителгән халыкларның бер үзенчәлегедер инде.

Нишлисең, мескен халыкның язучылары бәхетле була алмый.

Мин үз халкымның менә шундый бәхетсез бер баласы идем. Ул мәлләрдә мин үз бәхетсезлегемне аермачык күрә идем: яңа роман белән булашып, дөньямны оныткانмын – бурычка да хәтсез керелгән икән, ә түләргә бер тиен дә акчам юк. Һәм иң аянычы – тиз генә эшләп алырлык мөмкинлек тә юк иде. Әҗәткә сорап торырлык кешеләр турында авыз да ачасы түгел – монысы әйтмәсәм дә аңлашыладыр. Акча, әлбәттә, бәхетсез кешене бәхетле итә торган нәрсә түгел. Әмма аның бер серле ягы бар – кесәңдә акчаң бетсә, үзеңне мескен итебрәк тоя башлыйсың. Һәм күңелеңә корт булып оялаган шушы тойгы сине, чынлап та, мескенгә әйләндерә. Үз-үзеңне кимсетергә тотынасың… Ә бу дөньяда беркем дә (беркем дә!) сине үз-үзеңне кимсеткән дәрәҗәдә кимсетә алмый. Газапның иң зурысы – үз җаныңны үзең талаудыр ул.

Җанымның таланган чагы иде. Моңа, әлбәттә, тәннең хәлсезләнүе дә сәбәпче булгандыр. Соңгы әсәремнең соңгы ноктасын куюга, мин үземнең чиксез арыганлыгымны тойдым. Бу – берни белән дә тиңләп булмаслык алҗу. Тәнеңнең бөтен күзәнәкләре берьюлы һәм аерым-аерым хәлсезләнеп таркала башлагандай була. Син әкрен генә җебеп төшәсең…

Тәүлегенә ике-өч сәгать кенә йоклап, куе кофедан башка бернинди ризык та капмыйча айлар буена эшләгән иҗатчының бу халәтен аңларга мөмкиндер.

Компьютер артыннан торуга, мин чайкалып куйдым һәм, егылып китмәс өчен өстәлгә таянып, бертын басып тордым. Башымны артка борып, авып-нитеп китсәм аякны сузып иркенләп йокларлык урын эзләргә маташтым. Бүлмәдә эш өстәле белән китап шкафларыннан башка мебель юк иде. Кайда егылсаң да, как идәнгә төшәсең. Бары тик стеналарга башыңны бәрмәслек итеп кенә аварга кирәк. Бу инде өйрәнелгән нәрсә иде…

Кинәт хәлсезлек юкка чыккандай тоелды. Мин башта моңа аптырабрак калдым. Сәбәбен соңыннан гына аңладым. Ачык тәрәзәдән кергән тәмле аш исе сәбәпче иде. Авыздан сулар килде. Мин ирексездән тәрәзәгә тартылдым. Кемдер балык кыздыра иде. Тәрәзәдән карап кына тамагым туймасын аңлап, кухняга атладым. Аяклар мамык сыман тоелды. Мин ач идем. Һәм шушы ачлыктан бөтен тәнем калтырана иде. Дерелдәгән кулларым белән суыткыч ишеген ачтым һәм шатлыктан улап җибәрдем. Полиэтилен пакетта бер минтай балыгы калган иде. Аның эрегәнен дә көтеп тормастан, табага салдым. Мин балык яратам. Һәм аны кибеттән тактасы белән алып кайтып, көнендә үк тазартып, тозын-фәләнен сибеп әзерләп куям, соңыннан бары тик суыткычтан алып табага ыргытасы гына кала. Әле үземнең шушы гадәтем өчен сөенеп бетталмадым. Балык пешеп чыкканчы чәйни торырга берәр ризык юкмы дип, тагын суыткычны ачтым. Берни дә юк иде. Буп-буш. Икмәк савытында да моннан бер атна чамасы элек алынган йодрык зурлык булка кисәгеннән башка нәрсә табылмады. Мин аны шундук диярлек кимереп бетердем. Бер мизгелгә бу дөньяда каткан булка кисәгеннән дә тәмлерәк берни дә юктыр сыман тоелды. Һәм мин бу уемны бик мәзәккә күреп елмаеп куйдым. Ул арада балык пеште, һәм берничә секунд эчендә кылчыклары гына калды. Ул искиткеч дәрәҗәдә тәмле иде.

Мин, әлбәттә, туймадым. Ләкин тәнемнең калтырануы юкка чыкты, хәл кереп киткәндәй булды. Хәзер минем ашыйсы килү теләгеН җиңәрлек кенә көчем бар иде. Хәзер рәхәтләнеп йокларга да була.

Ләкин прихожийдагы көзге алдындагы кәгазьләрне күрүгә, йокы очты. Болар минем бурычлар иде: фатирга, телефонга, электр энергиясенә… һәм башкалар… Барлыгы сигез меңгә якын… «Тагын дус-ишләргә, таныш-белешләргә… – дип өстәдем мин күңелемнән. – Тагын шул тирә… Барлыгы уналты мең чамасы…» Бу миңа, кесәсендә бер тиен дә акчасы булмаган адәмгә, ярыйсы ук зур сумма иде.

Мин янә компьютер артына барып утырдым. Арыганлык та, ашыйсы килү теләге дә юк иде инде. Беркайда да басылмаган әсәрләремне кабат карап чыктым. Һәр повестем өчен бер генә мең сум түләсәләр дә, әлеге бурычларым миңа бик тә кечкенә булып каласы икән… Бер повесть өчен бер мең! Бу – искиткеч арзан хак, бушка эшләү кебек. Ләкин мин бөтен авторлык хокуклары белән аларны шул бер меңгә сатарга да риза идем. Ходай миңа талантны да, сәламәтлекне дә биргән. Мин яза алам, язам… Мондый әсәрләр әле тагын булып торыр… Миңа алар жәл түгел… Ләкин иң аянычы шул – ул повестьларны миннән хәтта шул бер меңгә дә алырга теләгән кеше юк иде.

Ярлылыгымнан бигрәк, кирәксезлегемне тою авыр иде. Әйе, мин әйбәт язучы. Әйе, талантлы. Күп эшли торган. Ләкин беркемгә дә кирәкмим. Үзем дә, әсәрләрем дә. Һәм бу – коточкыч.

Әлбәттә, тормышымның бөтен максаты баю яки акча табу гына булса, мин бик аптырап тормас идем. Башы эшләгән адәмгә бу – авыр нәрсә түгел. Аннан соң, минем кул-аяклар да яхшы эшли. Пистолеттан яхшы атам. Сугыша беләм. Хәтта гадидән-гади юлбасар гына булсам да, үз тамагымны үзем туйдырып, җитеш тормышта гомер итәр идем.

Ә язучы булып… Татар язучысы булып… Эх-х…

Күрәсең, мин милләт дип чәчрәп йөри торган кеше түгелмендер. Кайчагында җәмгыятьтәге процессларның тизрәк булуын көткән сыман тоелам. Югаласы милләтләр тиз генә югалсын да, бер генә халык булып яши башлыйк инде, дип уйлыйм. Җирдәшләр булып. Агонияне ник сузарга инде?! Һичьюгы, бер проблемадан – тел проблемасыннан азат булыр идек. Бер үк шартларда иҗат итәр идек. Ә үзем әлеге хәлне күз алдына китерә алмыйм. Төрле төбәкләрдә яшәгән халыкларның милли үзенчәлекләре юкка чыккач, әдәбият та югалыр сыман тоела. Югалмаса да, ул кызык булмас, ниндидер калыпка гына әверелер кебек. Белмим, бәлки, хаталанамдыр.

Мин үземнең хаталануымны телим. Әлеге уйларның чынбарлыктан ерак торуын телим. Аларны акчасызлык һәм күңел төшенкелеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән иллюзия генә итеп күрәсем килә. Ачлыктан тилмергән кешенең күзенә төрле шәүләләр, өрәкләр күренә башлый икән, дип ишеткәнем бар. Әлеге уйларның да авыр хәлдә яшәгән язучының күзенә күренгән шул өрәкләр сыман нәрсә генә булуын телим…

Белмим, уйлар ташкыны мине кайсы ярларга илтеп ыргытыр иде, бәхеткә каршы, телефон шылтырады. Мин бераз аптырап калдым. Моңарчы шылтыраганы булмагач, телефон турында бөтенләй онытканмын, акча түләмәгән өчен, аны күптән сүндергәннәрдер инде, дип уйлый идем. Һәм гаҗәпләнү катыш шатлык белән трубкага үрелдем. Шатлыгым баягы уйларның дөрес түгеллеге исбатлана башлаудан иде. Димәк, беркемгә дә кирәкмим диюем – хата, димәк, мин әле кемгәдер кирәкмен. Димәк, бүтән уйларым да…

– Илгизәр, хәлләрең ничек? – Бу тавыш миңа таныш иде. Концертлар алып баручы юморист егет Хәмит. Сатирик хикәяләр сорап шылтыратуыдыр инде. Минем дәшми торуымны өнәмичә, ул тагын кабатлады: – Хәлләрең ничек, дим!

– Әйбәт шул… – дип елмайдым мин, остазым Атнабайның2 сүзләрен кабатлап. – Үзем дә шуңа аптырап утырам әле…

– Сиңа бер йомыш бар иде…

– Беләм, – дип бүлдердем мин аны, – йомышың төшмәсә, хәл сорап шылтыратмыйсың инде син…

Ул минем сүзне ишетмәде дә бугай, үзенекен тезде:

– Мин әле гастрольдә йөрим. Бушамыйм. Бер эш бар иде. Кыскасы, болай. Бик абруйлы бер абзыйның юбилей кичәсен алып барырга кирәк. Музыкантлар да, җырчылар да бар. Кичәне алып барыр өчен, җор телле кеше кирәк. Синең кулыңнан килә ул. Әйдә, тәвәккәллә әле.

– Гомеремдә бер тамада булганым юк…

– Моның өчен әллә ни кирәкми. Җыелган кунакларның исемлеген аласың да, кызыклырак итеп сүз бирәсең. Алар сөйләп бетергәч, табындагыларны эчәргә кыстыйсың. Шул гына.

Минем, әлбәттә, табын алып барганым бар иде. Дусларның, туганнарның берәр бәйрәме булса: «Син язучы кеше, телгә остасың…» – дигән булып, бу эшне гел миңа йөклиләр. Һәм мин аны бик яратмый идем. Басып тост әйтеп аракы эчүне кем уйлап тапкандыр, белмим. Әмма мин моның бер кызыгын да күрмим. Ну, кунак кеше сүз әйтә инде, бәйрәмгә сәбәпче булган кешене мактаган була, янәсе ул әйбәт, изге күңелле, фәлән-төгән… Теге бахыр, бу сүзләрнең шыр-ялган икәнен белеп торган килеш, ышанып утырган була… Һәм табынның башыннан азагынача шул күренеш дәвам итә… Бәйрәм табыны колхоз җыелышы түгел ич инде… Әле дә Хәмитнең тәкъдименнән баш тартырга иттем. Тик ул, минем хәлне аңлагандай, тылсымлы сүз әйтте:

– Карышырга уйлама да! – диде ул, боерык биргәндәй итеп. – Беренчедән, баш тартсаң, мине авыр хәлгә куясың. Икенчедән, акча түлиләр. Әйбәт түлиләр. Биш мең.

– Нәрсә?! – мин үз колакларыма үзем ышанмый тордым. – Биш мең?

– Әйе. Сәгать дүртләр тирәсендә Октябрь проспектындагы ашханәгә кил. Анда сине Илнур каршы алыр. Безнең баянчы егет. Ул барысын да төшендерер. Ярый, хуш. Мин ашыгам.

Һәм ул трубканы ташлады.

Биш мең, әлбәттә, зур акча иде. Ләкин күңелне әрнетеп, тагын бер уй узды. Роман, повестьларны бер меңгә дә алучы юк, ә монда, нindидер табын өчен… Ләкин мин бу уйны шундук куып җибәрдем. Акча эшләргә комачаулап йөрмәсен…

Мин табын алып барырга бик яратмыйм, дигән идем. Ялгышканмын икән. Әлеге табынны алып барганда мин шуны ачык төшендем: яратмыйм дип әйтү дөрес түгел, мин бу эшне күралмыйм икән.

Дуслар табынындагы шикеллерәк булыр дип көткән идем. Бер өстәл артында утырасың, вакытын белеп кенә, кирәкле кешегә сүз бирәсең… Монда алай булмады. Беренчедән, килгән кунаклар, чынлап та, бик зур урыннарда эшли торган тәкәббер кешеләр иде. Безне алар белән бер табынга утыртмадылар. Чаршау артында аерым өстәл куйдылар. Әлбәттә, өстәлләре мул иде. Әмма бер табында утырмау мине, алып баручы буларак, авыр хәлгә төшерде. Бер өстәлдә утырганда, син үз кешегә әйләнәсең. Ә болай… Кешеләр сүз әйткән арада, мин, сөяк өмет итеп йөргән көчек шикелле, өстәл тирәсендә бөтерелергә мәҗбүр булдым. Ә бу кимсетә иде. Син бу табын кешесе түгел. Син чит. Син болар белән тиң түгелсең. Син аларны хезмәтләндерергә тиеш. Син – шушы табын артында утыручыларның хезмәтчесе. Кол. Ә мин үземнең кем икәнемне яхшы белә идем…

«Болар миннән ни ягы белән өстенрәк соң? – дип уйладым мин, табында утырган капкорсак яшьтәшләремне күреп. – Нинди зур эшләр майтарган алар шулай кылтаеп утырырлык?» Күңелне юатырлык җавап юк иде. Кайсын әтисе, кайсын абзыйсы юньле эшкә урнаштырган да кеше иткән. Боларның искитәрлек сәләтләре дә, үзләрен хезмәтләндерүче артистларга хөрмәт белән карарлык акыллары да юк иде. Вальс әйләнгәндә безнең җырчы кызны кармалап, муенныннан үбәргә маташкан утыз биш яшьләр тирәсендәге ирне сугып әйләндерәсем килде. Җырчыны адәмгә санамаса, үзе белән бергә килгән хатынын мыскылламасын иде. Кулында власть, кесәсендә акча булгач, аңа барысы да мөмкин дип уйлый, күрәсең… Тик мин беркемгә дә каты кагылмадым. Бары тик тәнәфес игълан итеп тәмәке тартырга чыккач кына, Илнурга зарланып алдым.

– Кем инде болар?.. – дидем мин, бер көтү булып төтен борхытып торган адәмнәр ягына ымлап: – Карале, ничек кыланган булалар! Алланың кашка тәкәләре диярсең… Безгә ничек

караганнарын күрдеңме?! Ниндидер кызыклы хайванга караган кебек… Кайсы ягы белән хаклы алар шулай кыланырга?

– Аларның акчасы күп, – дип пышылдады Илнур, – кем түли – шул музыка куя…

– Менә шулар җитәкли инде безнең халыкны… Шушы хайваннар безнең белән идарә итә…

– Син алай кызма әле… – диде Илнур, – нишлисең инде…

– Да пошли они… – Мин нәфрәт белән кулымдагы тәмәкене шулар ягына чиртеп җибәргәнемне сизми дә калдым. – Козлы вонючие…

Тәмәке төпчеге кемнеңдер ак чалбарына барып эләкте. Төркемдәгеләр безнең якка борылып карадылар һәм минем нәфрәт булып сыгылып чыккан сүгенүемне ишеттеләр. Табын хуҗасы минем янга йөгереп килде.

– Син!.. – диде ул, нәфрәтен җиңәргә тырышып. – Син үзеңне кем дип беләсең?!

– Гафу итегез… – дип сүзгә кушылды Илнур. – Без бөтенләй икенче нәрсә турында сөйләшә идек… Без сезнең хакта түгел… Һәм Илгизәр дә тәмәке төпчеген сезгә тидерергә теләмәгән иде… Шулай бит, Илгизәр?

Мин йодрыкларымны бәйдән ычкындырмаска тырышып кына тора идем. Бер сүз дә әйтә алмадым. Табын хуҗасының кыяфәте дә, Илнурның мескенләнүе дә миңа ошамый иде. Шулай да башымны кагарга мәҗбүр булдым.

– Мин синнән сорамыйм, – диде табын хуҗасы, – мин аның үзеннән ишетергә телим.

Әлбәттә, Илнур барысын да уңай гына хәл итә алырлык җавапны тапкан иде. Табын хуҗасы аек булса, моңа канәгатьләнеп китеп барыр һәм эшне зурга җибәрми калыр иде. Әмма ул ярыйсы ук исереп өлгергән иде шул. Һәм мин, ничек кенә җавап бирсәм дә, җәзасыз калмаячак идем.

– Әйе, – дидем мин, – тәмәке төпчеген сезгә дип ыргытмаган идем. Һәм «козлы вонючие» дигәнем дә сезгә түгел иде.

– Гафу үтен! – диде табын хуҗасы, күзен акайтып.

– Гафу итегез, – дип кабатладым мин көтелмәгән җиңеллек һәм битарафлык белән.

Ләкин бу табын хуҗасына ошамады.

– Син адәмчә итеп гафу үтен!

– Һмм… – Мин елмаеп куйдым һәм шундук, йөземә ясалма мескенлек чыгарып, табын хуҗасының күзенә текәлдем: – Сезне сасыган кәҗә дип атамаган һәм тәмәке төпчеген сезгә дип ыргытмаган өчен гафу итегез.

Сул яктан котылгысыз тизлек белән якынлашкан нәрсәне күреп, шундук артка янтайдым, һәм кыска буйлы, таза гәүдәле табын хуҗасының йодрыгы борын төбемнән исән-имин генә узып китте. Абзый ипкә килерлек түгел, ә минем эшне зурга җибәрергә теләк юк иде. Үзем генә булсам – бер хәл, минем аркада бөтен артистлар да ач калырга мөмкин. Мин шуларны уйладым да тынычлана төштем. Бәхеткә каршы, кемдер табын хуҗасын култыклап читкә алып китте.

– Күңелегезгә авыр ишетелсә, чынлап та, гафу итегез, – дидем мин, безне тамаша кылган төркемгә карап, – мин сезне кимсетергә теләмәгән идем.

– Без бөтенләй бүтән темага сөйләшә идек… – дип элеп алды Илнур.

– Ярый, – дип елмайгандай итте берәү, мин аның исем-атын хәтерләмим инде, банкир иде бугай. – Без аңлыйбыз… Бары тик хуҗа гына йомшара төшкән… Сез, егетләр, эшегезне дәвам итегез…

Һәм аның сүзе белән бөтенесе дә үзгәргәндәй булды. Баштарак безгә гайре табигый нәрсәгә карагандай аптырау катыш нәфрәт белән баккан күзләр бераз нурлана төште. Аннан соң, табында шаян сүзне аңлаган, югары бәяләгән кешеләр дә юк түгел, һәм минем шаярулар аларга ошый иде. Ә кайберләре хәтта минем язучы икәнемне дә белә… Хәер, монысы кичә беткәндәрәк кенә ачыкланды. Тәнәфес азагына озын буйлы яшь кенә бер ир килеп җитте. Аны күрүгә,

барысы да урыннарында тибрәнеп куйгандай тоелдылар. Ул, ишек төбенә җитүгә, барыбыз белән дә күрешеп чыкты. Дөресрәге, ул иң беренче минем белән күреште…

Банкирның сүзеннән соң без залга керергә дип борылган идек инде. Әмма шундук кереп китүне яхшысынмыйча, мин тәмәке алып кабыздым. Нәкъ шул вакытта караңгы тәрәзәле джип килеп туктады, һәм аннан озын буйлы бер ир чыкты. Кыска җиңле ак күлмәктән. Яшькә ул миннән артык зур булмагандыр. Беренче күрүдән үк ул миңа үз кеше булып тоелды. Моның хәрәкәтендә үзен әллә кемгә кую, башкаларны кимсетү кебек нәрсәнең эзе дә юк иде. Аны күрүгә, баскычның икенче ягында тәмәке көйрәтеп торган төркем тибрәнеп куйды. Кемдер аңа каршы омтылып та алды бугай. Әмма теге кеше туп-туры Илнур белән безнең янга атлады. Һәм иң беренче булып миңа кул бирде.

– Хәлләр ничек, Илгизәр?! – дип елмайды ул һәм, мин «әйбәт» дип баш каккач, өстәп куйды: – Синең хәлләр мотлак әйбәт булырга тиеш. Яхшы язучы син. Мин укып барам…

Мин бу адәмне белми идем. Шуңа сүз озынайтып тора алмадым. Ул Илнур белән күреште дә баскычның теге ягына атлады. Без Илнур белән залга уздык. Бераздан яныбызга табын хуҗасының улы йөгереп килеп җитте.

– Бераз үзгәреш бар, – диде ул, каш астыннан миңа сөзеп карап. – Тәнәфестән соң иң беренче сүзне Даутовка бирәбез. Абрар Муса улына.

Кунаклар табынга утырып беткәч, безнең җырчы кыз бер җыр җырлады да, мин, шуңа бәйләп, Абрар Муса улына сүз бирдем. Кызык кына килеп чыкты. Хәтта табындагылар кул чабып ук җибәрде. Мин, әлбәттә, бу алкышларның минем шаяру өчен түгеллеген белә идем. Шулай да күңел күтәрелеп китте. Ә Даутов, микрофонны алып:

– Рәхмәт, Илгизәр… – дигәч, бигрәк тә. Чөнки минем исем ишетелү белән, табында чыш-пыш китте. Мин аларның нәрсә турында икәнен чамалый идем. «Туктале, кем соң бу егет?! Абрар Мусаевич аны каян белә? Әллә дуслар микән?» Кыска вакытлы пышылдашулар шул хакта иде.

Әлбәттә, исеменең кемнеңдер авызыннан ишетелгән өчен генә ниндидер мәгънәгә ия булуы язучы өчен бик күңелле күренеш түгел. Әмма бу начар да булып чыкмады. Табындагыларның безгә алар күңелен күрер өчен килгән артистларга булган карашы бөтенләй үзгәрде. Алар безне башта үзләре белән тиң күреп, ә соңрак хәтта бераз югарырак куеп аралаштылар. Соклануларын белдерергә дә, танышлары һәм кыз-уллары өчен автографлар сорарга да тартынмадылар. Һәм без дә аларга халык җилкәсендә утыручы сорыкортлар итеп түгел, ә чын-чынлап дәрәҗәле һәм абруйлы кешеләр сыман итеп карадык.

Ә бер арада Абрар Муса улы, бөтен табынга күренерлек итеп, миңа үзенең визиткасын сузды:

– Киләсе дүшәмбедә минем янга кагылып чык әле, Илгизәр.

– Дүшәмбедә булмый, – дип бүлдердем мин, – әйдәгез, сишәмбегә калдырыйк.

– Бик хуп, – дип елмайды Даутов, – килештек.

Бүген җомга, иртәгә туйганчы йоклап, ял итеп алсам, якшәмбе һәм дүшәмбе көннәрдә яңа әсәрне тагын бер кат карап-төзәтеп чыгармын дип, үзем өчен күптән хәл итеп куйган идем. Мондый эштән мине үлем, яки замана ахры, яки шуңа охшашрак тагын берәр нәрсә генә бүләргә мөмкин. Даутовның тәкъдименә каршы килүем бары тик шуннан гына иде. Ләкин очрашуны кичектерүем табындагылар арасында тагын ниндидер аңлашылмаучылык тудырды. Алар, әлбәттә, бернәрсә дә дәшмәделәр, әмма бер-берсенә сәер карашлар атып, иңнәрен сикерткәндәй итеп куйдылар. Һәм миңа булган мөнәсәбәтләре тагы да ныграк үзгәрде: баштагы мәлләрдә бик уңышлы шаяруларымны да игътибарсыз калдырсалар, хәзер шаяруга охшаган һәр сүзем саен диярлек көлеп, һичьюгы елмаеп алырга тырыштылар. Аларның бу кыланышы миңа да бик кызык булып тоелды һәм күңелемне күтәреп җибәрде. Ә икенче тәнәфескә чыккач, җаен туры китереп, кунакларның барысы да диярлек миңа үзләренең визиткасын бирде, вакытым булганда яннарына кереп чыгуымны үтенделәр.

Табын хуҗасының миңа булган ачуы да бик тиз онытылды. Ул вәгъдә ителгән акчасын тоттырып, һәрберебезнең аркасыннан сөеп озатты. Хәтта миннән гафу да үтенергә онытмады: «Артыграк киткән. Сез, берүк, кичерә күрегез инде…» Мин, әлбәттә, әлеге сүзләр астында Даутовның безгә булган мөнәсәбәте ятканын бик яхшы төшенә идем.

Табын хуҗасын берсүзсез гафу иттем. Хәтта акчасын алгач рәхмәт тә әйттем бугай әле. Тагын шундый өч-дүрт табын алып барырга кушсалар да, бурычларымнан тулысынча котылуымны уйлап, шатланып риза булачак идем. Бернәрсә дә бушка гына килми. Һәрнәрсә өчен дә түләргә кирәк. Арурак акча эшлим дисәң, кимсенүләргә дә түзәргә туры килә. Бүгенге табында утырган әфәнделәрнең калын кесәсе нигезендә дә шул мыскыллауларга түзә белү ята иде. Үзеңнән өстенрәкләргә ялагайлана белү. Үзеңне адәмгә дә санамаган бәндәләрнең табанын ялый белү. Бу – җиңел нәрсә түгел. Бүген мин аны үз иңемдә тойдым. Шушы авырлыкка түзүләре, түзә алулары белән генә дә алар җитеш тормышка хаклы иделәр. Һәрхәлдә, миңа шулай тоелды. Һәм мин безгә көчеккә карагандай карап та, Даутов алдында калтырап төшкән кунакларны аңлагандай булдым.

Менә шундый хәлләр.

Бу дөньяда аңлап һәм аклап булмастай бер генә кабахәтлек тә юк бугай.

* * *

Барысы да гади генә бәхәстән башланды, дигән идем…

Теге табында мин Даутовны беренче тапкыр күргән идем. Сишәмбегә кадәр, аның турында тулырак мәгълүмат тупларга тырышып, белгән-күргәннәрдән сораштырып карадым. Тик алган мәгълүматым бик тә фәкыйрь булып чыкты. Нефть белән бәйле эшкуар, бик бай адәм. Президентның бик якын кешесе. Бары шул. Аның башкарган вазифасын да, нефть җитештерүнең кайсы тармагында эшләвен дә, туган-үскән җирен дә тәгаен белгән кеше табылмады. Хәер, акчаны һәм властьны Алла итеп күргән дәвер кешеләре өчен болар кызык та булмагандыр. Аның байлыгы һәм Президентка якынлыгы үзе генә дә тылсымлы көчкә ия иде.

Аның бай һәм кодрәтле шәхес булуына мин дә битараф түгел идем. Күңелнең кайсыдыр бер почмагына оялаган шайтан: «Менә шундый кеше сиңа спонсор булса…» – дип, туктаусыз рәвештә пышылдый сыман иде. Хәтта спонсор булмаган хәлендә дә, китапларымның нәшрият табасыннан туктаусыз төшеп торуы өчен мондый абруйлы затның бер сүзе җитәчәк. Аның шул сүзе булганда, «Китап» нәшрияты директорының: «Биш елга бер генә…» – дию бик тә мескен булып калачак иде. Һәм мин бар күңелем белән әлеге кысыр хыялларның чынга ашуын теләдем. Хәтта Үзәк базар янында утырган теләнче карчыкка ун сум хәер тоттырдым. Мин аның дога кылуын, һичьюгы ишарәтен китереп битен сыйпап куюын көткән идем. Ләкин ул ике кулы белән беләгемә чат ябышты да күзләремә текәлде.

# Конец ознакомительного фрагмента.

Текст предоставлен ООО «ЛитРес».

Прочитайте эту книгу целиком, купив полную легальную версию на ЛитРес.

Безопасно оплатить книгу можно банковской картой Visa, MasterCard, Maestro, со счета мобильного телефона, с платежного терминала, в салоне МТС или Связной, через PayPal, WebMoney, Яндекс.Деньги, QIWI Кошелек, бонусными картами или другим удобным Вам способом.